КУЛ ЖЫЛЫСЫ

«ВТ» хәбәрчесе итекчеләр һәм шәлчеләрнең хәлләрен белеште

> 5

ӘЙ, ЮЛЛАР...

Ишеп яуган карны җыештырып бетерергә көрәк җитәрме?

> 7

ЯШЬ КҮҢЕЛ

Юбилеен бәйрәм итүче хезмәттәшебез Риман Гыйлемханов үзе турында үзе сөйли

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 7 (29167) | Җомга | 19 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КЫШ КӘЕФЕ

КӨЙСЕЗ ҺАВА ТОРЫШЫ НӘРСӘ ТУРЫНДА СӨЙЛИ?

Нәкъ безнеңчә кыш килде! Өлкән буын әнә шулай дип сөенсә, замана яшьләре, тәмам туйдырды инде, дип, табигатьне сүгә. Халык синоптиклары әйтүенчә, кыш үзенекен итәчәк. Суыклар озакка сузылырмы? Җәйгә фаразлар нинди? «ВТ» хәбәрчесе алга таба нинди һава торышы көтәргә икәнне белеште.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда, үлем-китем күрсәткече кимеп, яңа рекорд куелган. Сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Абашев әйтүенчә, Советлар Союзы таркалганнан соң (1991 елдан бирле) тәүге тапкыр үлем-китемнең иң түбән күрсәткеченә (1000 кешегә – 10,7 кеше) ирешелгән. Аның сүзләренә караганда, моңа кадәрге иң яхшы нәтиҗә (1000 кешегә – 11 кеше) 2019 елга туры килә. Шул ук вакытта республикада уртача гомер озынлыгы 75,38 яшькә җиткән.

Узган елда Татарстанда яшәүчеләргә сыйфатсыз хезмәт өчен яки сыйфатсыз товар өчен түләнгән 127 миллион сумнан артыграк акча кире кайтарылган.

Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина сүзләренә караганда, 2023 елда ведомство вәкилләре 1,5 меңнән артыграк суд утырышында катнашкан. «Тере яки бу хосусый эшмәкәргә яки җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә карата шикаятьләр бер кешедән генә түгел, ә күпләрдән алынган очракта, күмәк дәгъва тапшырабыз. Болай эшләү кешеләргә китерелгән матди зыянны раслауны җиңеләйтә», – дигән ул.

Казанда яңа уку елына тагын 3 яңа мәктәп ачылачак. Шулай итеп, «М-14» микрорайонында, «Весна» һәм «Родина» торак комплексларында яңа уку йортлары барлыкка киләчәк.

Декабрь азагында 19 нчы гимназиянең ике катлы яңа бинасы төзелеп беткән. Ул 300 балага исәпләнгән. Шәһәр мэры Илсур Метшин әйтүенчә, биредә укучыларның белем алуы гына түгел, бәлки төрле яклап үсүе өчен дә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. «Балалар тормыштан канәгать булып үссеннәр өчен, барын да эшлибез. Казан социаль объектлар төзү буенча алдынгылыкта бара. Без бу юнәлештән читкә тайпылмаячакбыз», – ди мэр.

Бу уку елында Татарстан башкаласында: Совет (184 нче гимназия бинасы), Яңа Савин (107 нче гимназия), Киров (182 нче политехника лицее) һәм Идел буе (186 нчы лицей) районнарында барлыгы 6 мең укучы өчен 4 яңа мәктәп ачылган. Соңгы дистә ел эчендә шәһәрдә җәмгысы 90 балалар бакчасы һәм 25 мәктәп калкып чыккан.

Ел башыннан бирле Татарстанда суд приставлары юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафка тартылган йөртүчеләрдән 12 миллион сум түләткән. Шулай итеп, 60 көн эчендә штраф түләмәүчеләргә генә түгел, бәлки эш суд приставларына тапшырылганнан соң да тыныч кына йөрүчеләргә бурычларын капларга туры килгән.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Шәһәрдәге яңа «Урман» торак комплексында халык шагыйре Разил Вәлиев исемендәге урам барлыкка киләчәк. Бу хакта район Башкарма комитеты җитәкчесе Роман Булатов рәислегендә узган топонимика комиссиясе утырышында билгеле булды. «Урман» торак комплексында 25,8 гектар мәйданда 133 шәхси йорт, 60 таунхаус һәм күпфатирлы йортлар төзеләчәк. Хәзерге вакытта комплекста өч кечкенә урам билгеләнгән.
(e-nkama.ru)

Менделеевск

Мәскәүдә «Кече Ватан – Россиянең көче» бөтенроссия форумында Россиянең икътисадый үсеш министры Максим Решетников Менделеевск районының Татар Чаллысы авыл җирлеген һәм авыл җирлеге башлыгы Татьяна Кузнецованы бүләкләде. Татар Чаллысы авыл җирлеге «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия бәйгесендә «Муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр белән нәтиҗәле элемтәне тәэмин итү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү һәм җирле үзидарәне башка формаларда гамәлгә ашыруга гражданнарны җәлеп итү» номинациясендә икенче урынга лаек булды. 12 млн 750 мең сум күләмендәге премия авыл җирлеген үстерүгә тотылачак.
(«Татар-информ»)

Зәй

Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рабит Батулла районда якташлары белән очрашулар уздыра. Аксакал язучы Баграж, Түбән Биш, Кушъелга һәм башка авылларында үз әсәрләрен яратып укучылар, якташлары белән очрашты. Аксар, Югары Шепкә авылы мәктәпләрендә булып, укучыларга әдәбият, татар халкы тарихына кагылышлы бай мәгълүмат бирүче дәресләр үткәрде. Укучылар сорауларына җавап бирде. Китап укучылар белән очрашу Иманлебаш китапханәсендә үтте. Югары Шепкә авылы мәктәбендә ул дини мәгърифәт темасын күтәрде.
(«Зәй офыклары»)

Мамадыш

Көек-Ерыкса авылында махсус хәрби операциядә һәлак булган Руслан Фәлахетдинова истәлек тактасы ачылды. Батырлык ордены, «Генерал армии Маргелов» һәм «За разминирование» медальләре белән бүләкләнгән Руслан 2023 елның 8 ноябрендә һәлак була. «Ул махсус хәрби операция зонасында булганда, телефоннан сөйләшә идек. Гуманитар йөк илтүчеләр белән бергә барып, үзе белән өч мәртәбә күрешергә насыйп булды. Өч мәртәбә контузия алган булып чыкты, берсен дә безгә әйтмәде», – дип сөйли улы турында Русланның әтисе Илнур Фәлахетдинов.
(«Нократ»)

ИРТӘГӘ БҮГЕН БАШЛАНА

Ут һәм су өчен түләгәндә үтә күренмәлелекне тәэмин итү, «акыллы» Казан һәм нәселдән килгән чирләр. Башкалада Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе утырышы узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

tatarstan.ru

Ризасызларны тикшерәләр

Чара «Татэнергосбыт»ның башкаладагы оешмаларының берсендә узды. Шуңа күрә сөйләшү дә аның эшен бәяләүдән башланды. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, «Татэнергосбыт» республикада 2009 елдан бирле эшли һәм электр энергиясеннән, торак-коммуналь хезмәтләрдән файдаланучылар белән аны җитештерүчеләр арасында үзенә күрә бер күпер булып тора.

> **– Әлеге оешма базасында барлыкка килгән Бердәм исәп-хисап үзәге кулланучыларга күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатын гына яхшыртып калмыйча, түләүләрне җыюның үтә күренмәлелеген дә тәэмин итте, – диде Рөстәм Миңнеханов.**

Тик Татарстандагы оешмаларның барысы да әлеге системага кушылырга ашыкмый икән. Бу хакта утырышта ассоциация советы рәисе, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов әйтте.

– Республиканың җиде районы «Татэнергосбыт» инфраструктурасына тоташмаган килеш кала. Башка компанияләрдән энергия сатып алучы зур предприятиеләр белән энергия белән тәэмин итү килешүләрен төзү мәсьәләсе дә ачык. Татарстан Рәисе тарафыннан бирелгән күрсәтмәләргә карамастан, республикадагы 13 компания әлеге эшне башкармады әле. Андыйлар белән эшне көчәйтергә тәкъдим итәм, – диде Рифкать Миңнеханов.

Әлеге фикерне куәтләп, Рөстәм Миңнеханов бу мәсьәләне игътибарга алырга, бигрәк тә Бердәм исәп-хисап үзәгенә күчәргә теләмәгән идарәче компанияләрне тикшерергә киңәш итте.

– Торак инспекциясе, прокуратурага да мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Тикшерсеннәр. Аннары алга таба нишләргә икәнен уйларбыз. Без бит бернәрсә дә таләп итмибез! «Татэнерго» моннан акча эшләми. Түләү системасының төгәллеге, үтә күренмәлелеге тәэмин ителәчәк кенә, – диде Татарстан Рәисе.

«Акыллы» Казан

Казанны мактадылар. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан башкаласы – иң «акыллы» шәһәрләрнең берсе.

– Казан ил күләмендә «акыллы шәһәр»ләр рейтингында алдынгы урыннарның берсендә тора. Шәһәрдә процессларны һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру юнәлешендә бай тәҗрибә тупланган, – диде ул.

Баксаң, «акыллы»лар исемлегендә без Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышабыз икән. Шул ук вакытта, ил башкаласы белән чагыштырганда, бездә цифрлаштыруга киткән чыгымнар 30 тапкыр кимрәк.

Татарларга хас авыру

Утырышта чыгыш ясаган «БАРС Груп» җитәкчесе урынбасары Эльвира Гыйльманова исә чараны җиргә тартып төшергәндәй, нәселдән килгән авырулар турында сөйләде. Республикада яшәүчеләрнең генетик мәгълуматын аерым бер базага тупларга тәкъдим итте ул. Дөрес, бу хакта күптән сөйләшәләр. Шунысы да бар: әлеге мәгълүматны җыю гына түгел, аны саклау, куркынычсызлыгын тәэмин итү дә бик мөһим. Әби-бабаларыбызның бөтен авыруларын туплап, мәгълүматны цифрлаштыру алга таба яңа туган балалар арасында генетик авыруларны булдырмый калу, нәсел чирләрен алдан ачыклау мөмкинлеген тәэмин итәчәк, диделәр утырышта.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин әйтүенчә, РКБ әлеге юнәлештә күптән эшли. Аерым алганда, йөкле хатын-кызларга скрининг ясап, төрле авыруларны алдан тикшерәләр. Министр әлеге эшнең мөһимлеген һәм тирәнтен өйрәнү таләп ителүен дә искәртте. Мәсәлән, генетиклар шуны ачыклаган: татарлар арасында ашказаны яман шеш авыруы килеп чыгу куркынычы зур икән.

– Без юл башында гына. Безгә ничек килеп чыгуыбыз, тарихыбыз мөһим. Генетик тикшерүләр бу юнәлештә ачыклык кертергә булышачак дип уйлыйм. Эшне дәвам иттерергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аңа җавап итеп, Рифкать Миңнеханов: «Кайбер мәсьәләләрдә тарих үзгәрергә дә мөмкин», – дип тә өстәде. «Тарих үзгәрмәячәк. Ул кайберәүләр уйлап чыгарып язганча түгел, ә дөрес булачак», – дип җавап бирде Татарстан Рәисе.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БУЛГАННЫ АРТТЫРАСЫ

Вузларыбызның активлыгы аркасында узган ел Татарстан ил төбәкләренең фәнни-технологик үсеш рейтингында икенче урынга күтәрелде. «Планетаның сыек углеводородларын рациональ үзләштерү» дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәкнең халыкара күзәтчелек советы утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде.

– Республикада «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты тарафыннан каралган барлык белем бирү һәм тикшеренү инфраструктуралары уңышлы гына эшләп килә. Бу хакта гел әйтеп киләбез, – ди Рәис. – Узган ел алар сафына алдынгы ике инженер мәктәбе өстәлде. Федераль бюджет һәм индустриаль хезмәттәшләрнең финанс ярдәме белән алар Әлмәт дәүләт нефть институты белән Казан илкүләм тикшеренү техник университетында да булдырылды. Татарстанда эшләп килүче технология университеты, үз чиратында, «Приоритет 2030» программасының махсус өлеше составына кертелде.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда укучылар әзерләгән 442 проектның «Студентлар стартапы» бәйгесендә җиңү яулаганын да искәртте. Рәис Ромашкино нефть чыганагыннан озак вакыт дәвамында файдалану барышында Татарстанның фән тармагы белән сәнәгатьнең углеводород чималының авыр табыла торган запасларын да үзләштерергә өйрәнүен дә билгеләп үтте.

– Хәзерге вакытта бу белем һәм тәҗрибәгә дөньяның нефть табучы күп кенә илләрендә сорау зур. Булган теоретик һәм гамәли белемнәрне арттырырга кирәк. Шул максаттан совет әгъзалары рәтенә үзебезнең һәм чит илләрнең углеводород чималы тармагында хезмәт куйган әйдәп баручы белгечләре кертелде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

ЫШАНЫЧЛЫ КЕШЕЛӘР

Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, «Ак барс»ның элеккеге капитаны Данис Зарипов, «Ярдәм янәшә» республика хәрәкәте координаторы Ринат Фазылов, мөмкинлеге чикле кешеләргә ярдәм итүче «Я смогу» оешмасы җитәкчесе Марат Ильясов, хәйрияче һәм җәмәгать эшлеклесе Алинә Гыймалтдинова, җырчы Салават Фәтхетдинов. Россия Президенты вазыйфасына кандидат Владимир Путинның Татарстан төбәк сайлау штабы ышанычлы затлары бу. Шушы көннәрдә алар белән республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов очрашты.

– Президент һәрвакытта да күпмилләтле халкыбызга таянды. Быелгы сайлауның нинди тышкы сәбәпләр шартларында узуын беләбез. Татарстанда сайлау эшчәнлегенә тыкшыну, вазгыятьне тотрыксыз итүләргә юл куелмас, – диде Рөстәм Миңнеханов очрашуда.

Рәис искәрткәнчә, хәзер илнең казанышлары турында сөйләү аеруча мөһим. Бигрәк тә мисаллар, үрнәкләр ярдәмендә. Халык белән элемтәдә булу да кирәк. «Хәзерге вакытта хакимият халык мөрәҗәгатьләренә аеруча игътибарлы булырга тиеш», – диде ул.

Тышкы басымга карамастан, 2023 елда республикада барлык программалар гамәлгә ашырылган, объектлар вакытында кулланышка тапшырылган.

– Болар барысы да федераль ярдәм булганда гына мөмкин. Федераль ярдәм булмаса, без мондый уңышларга ирешә алыр идекме? Иң мөһиме – тормыш сыйфаты. Ни өчен туристлар, бик теләп, Казанга, республикага килә? Кешеләр безнең республикага күченә? Халык саны кимеми, югыйсә кайбер төбәкләрдә бу да бар. Без 4 миллионнан арттык. Безнең халык моның дәүләт башлыгы кайгыртуы, аның программаларга, безнең республикага шәхси мөнәсәбәте икәнен аңларга тиеш, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

ВЫБОРЫ
ПРЕЗИДЕНТА
РОССИИ
15–17 МАРТА 2024

Ышанычлылар белән очрашуда Дәүләт Киңәшчесе, Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашты. Дәүләт Киңәшчесе Путинның ышанычлысы сыйфатында Татарстанда тиешле эш алып барачагын әйтте. Очрашуда Россия Герое Рәсим Баксиков, Анжела Вавилова исемендәге фонд җитәкчесе Владимир Вавилов, «Zа Победу! Казань» халык гуманитар хәрәкәте оештыручысы Евгения Коцарь һәм башкалар катнашты.

Белешмә өчен

Россия Президентын сайлау 15, 16 һәм 17 мартта була. Үзәк сайлау комиссиясенә 15 кандидат документларын тапшырган, аларның дүртесен теркәүдән баш тартканнар. Шул рәвешле, документлар 11 дәгъвачыдан, шул исәптән сайлауда үзен үзе тәкъдим итүче хәзерге дәүләт башлыгы Владимир Путиннан кабул ителде. Хәзерге вакытта сайлауга өч кандидат – Владислав Даванков («Яңа кешеләр» партиясеннән), Леонид Слуцкий (ЛДПРдан) һәм Николай Харитонов (КПРФтан) кертелгән инде.

СЫЙФАТСЫЗГА УРЫН ЮК

Татарстанда йогышлы чирләр белән авыручылар саны арта, кибет киштәләрендә сыйфатсыз ризык кими. Кулланучылар хокукы игътибар үзәгендә кала бирә. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсенең узган елгы эш йомгакларын кыскача гына шулай бәяләп булыр иде.

Идарә башлыгы Марина Патяшина еллык коллегия утырышын көн кадагындагы мәсьәләдән – инфекцияле авырулардан башлыйсы итте. Белгечләр яшерми: коронавирус аркасында кертелгән пандемия рәсми рәвештә тәмамланса да, бу чирнең нәтиҗәләре әле үзен бик озак сиздерәчәк.

– Коронавирус иммунитетыбызга бик зур зыян салды. Шул сәбәпле республикада 26 төрле инфекция белән авыручылар саны артты. Аларның күбесе күпьеллык уртача күрсәткечләрдән дә артып китә (таблицада. – **Д.Г.**), – диде Марина Патяшина.

Узган елның зур шау-шу тудырган иң мәкерле инфекцияләре дип идарә башлыгы кызамык белән коклюшны атый.

Инфекцияле авырулар үзгәреше – саннарда

	Арту	
	2022 ел белән чагыштырганда	Күпеллык уртача саннар белән чагыштырганда
Кызамык	147 тапкыр	20,2 тапкыр
Коклюш	137 тапкыр	10,3 тапкыр
Грипп	3,5 тапкыр	8,8 тапкыр
Хроник С гепатиты	79 процентка	37 процентка
Норовирус инфекциясе	21 процентка	2,9 тапкыр
Тычкан бизгәге	16 процентка	33 процентка

– Узган ел, иң беренче чиратта, кызамык борчуга салды. Аны, нигездә, бу чиргә каршы вакцина ясатмаган кешеләр йоктыра. Кызамык белән авыручы һәр ике кешенең берсе – мигрант. Узган ел коклюш та баш калкытты. Әлеге чир күбрәк 7–14 яшьлек балаларны аяктан ега. Бу аңлашыла да. Әлеге яшь аралыгында балаларга кызамыкка каршы ревакцинация уздырылмый. Шуңа күрә без республика дәрәҗәсендә ревакцинация керттек. Шул рәвешле 4–7 яшьлек 30 меңнән артык балага коклюшка каршы прививка кабат ясалды, – ди идарә башлыгы.

Патяшина тычкан бизгәген дә телгә алды. Республикада аны йоктыручылар саны 2022 елдан бирле үк арта бара. Узган ел исә аларның саны 16 процентка күбәйгән. Былтыр республикада грипп очраклары да 4,5 тапкыр арткан. Яңа ел башыннан бирле Татарстанда берьюлы өч төрле вирус – грипп, коронавирус һәм ОРВИ белән авыручылар да пәйда булды. Белгечләр тридемия белән авыручыларның төгәл санын атый алмаса да, февраль – март айларында алар кимеячәк, дип ышандырды.

Идарә белгечләре ризык сыйфаты белән кулланучылар хокуклары сагында да тора. Узган ел алар 47 тоннадан артык сыйфатсыз ризыкны әйләнештән алган. Бу алдагы ел белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк.

– Тикшерү барышында кайбер төр яшелчә-җиләк-җимештә, камыр ризыклары, ит һәм сөт ризыкларында зарарлы микроорганизмнар табылды. Тикшерүгә алынган 23 проба ризыкта пестицидлар булу ачыкланды. Читтән кертелгән азык-төлекнең дә яртысыннан артыгында шул хәл. Әйтик, Кытайда җитештерелгән чәй, Төркиядән кертелгән груша, лимон, борычта да зарарлы матдәләр табылды. Алар барысы да әйләнештән алынды, – ди Патяшина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы сүзе

Ышандыру

Кем син? Беренче карашка гади генә тоелган кайбер сорауларга бер уйламый җавап биреп булмый. Бу да әнә шундый. Әллә ничә төрле җавабы бар һәм берсе дә төпле булмаска мөмкин. Кем син? Исемеңне атадың ди. Тик ул исем берни дә аңлатмый. Исемнәр күп, ә син берәү генә. Исеме нәрсәдер аңлатсын өчен, кеше кемдер булырга тиеш. Кем син? Һөнәреңне әйтергә була. Язучы ди, мәсәлән. Беләсеңме дөньяда күпме язучы бар? Белмисең. Аны беркем дә белми. Кайбер исәпләр буенча, язучылар бүген язмаучыларга караганда да күбрәк. Син шуларның кайсы? Милләтеңне әйтә аласың. Татар. Яки рус. Яки... Әнә ул да татар. Тик син ул түгел, син аннан ничектер аерыласың. Бармак эзләре буенча гына түгел бит инде. Женес... Әйе, җенесеңне дә әйтә аласың. «Мин – ир кеше!» Ләкин ирләр дә күп...

Кем син?

Бу сорауга бер сүз белән генә җавап биреп тә булмый бугай әле. Чөнки син үзеңнең кемлегеңне үзең генә билгеләмисең. Синең кемлегеңне тирә-ягыңдагылар билгели. Әлбәттә, син ирекле, үзеңне президент та, фәрештә дә, даһи дип тә уйларга мөмкинсең. Һәм син халкы. Синe үзеңнән дә ныграк беркем дә белми. Белә дә алмый. Син үзеңне үзең кем дип уйлыйсың, син – шул. Фәкать шулай гына. Ләкин тирә-ягыңдагылар сине «бомж» дип уйлый икән, син – бомж.

Безнең кем булуыбыз тирә-ягыбыздагыларның безне ничек күрүеннән һәм уйлавыннан гына тора. Әйбәт язучы, мәсәлән, танылган, китапларын яратып укыйлар. Аны барысы да талантлы, язган әсәрләрен мәдәният өчен бик әһәмиятле дип уйлый. Һәм ул нәкъ шундый язучыга әверелә. Ә икенче көнне тегене ни сәбәптәндер бөтенләй бүтән төсмердә күрә башлыйлар. Талантсыз ул, үз-үзен генә яратучы, фәкать акча өчен генә яза һәм әсәрләренең бер әһәмияте дә юк. Фәлән гасыр буена Җир шары бу кешедән һәм аның әсәрләреннән башка әйләнгән һәм тагы әллә ничә гасыр буе әйләнәчәк. Ә бу... Өченче көнгә тегене бөтенләй дошман итеп күрә башлыйлар. Һәм әле кайчан гына аның исемен ишетү белән балкып китә торган, аның китапларын эзләп, фәлән бәягә сатып алып, кинәнеп укый торган кешеләр аны дошман дип уйлый башлый. Ул дошманга әйләнә.

Язучы гына түгел, бөтен кеше дә шулай. Патша ни өчен патша? Юк, аңа чиксез власть бирелгән өчен генә түгел. Сәбәбе фәкать бер генә: чөнки аны бөтен кеше дә патша дип уйлый. Әгәр кинәт бөтен кеше дә аны патша түгел дип уйлый башласа, аны шундук тәхет янынннан куып җибәрәләр. Хәтта әти-әниләр дә. Әгәр сез үз әтиегезне түгел, ә күрше ирен әти дип уйлыйсыз икән... Башкалар да шулай дип уйлый икән... Хәтта үз әтиегез дә сезнең әти булуына тuktый. Хәтта ул үзе дә моңа ышанмый башлый.

Квант физикасында кечкенә кисәкчекләр хәрәкәтен билгеләгән канун кешеләргә карата да эшли. Чөнки адәм балалары да кечкенә кисәкчекләрдән тора. Шуңа күрә синең кем булуың беркемгә дә кирәкми, үзеңнең кем икәнеңә башкаларны ышандыруың мөһим. Һәм безнең гомеребез асылда нәкъ менә башкаларны ышандырырга тырышудан тора. Мин үземнең язучы икәнемә ышандырырга тырышам, шуның өчен әйбәт әсәрләр язам... Әйбәт килеп чыкмаса, тәзәтәм... Әйбәт икәнен беркем дә күрмәсә, үзем мактый башлыйм... Ир икәнемә ышандырырга тырышам. Гаиләне тәэмин итәргә, тәртиптә тотарга, кимхур итмәскә... Әти икәнемә ышандырырга... Барыбыз да шулай. Хәтта патшалар да. Кем беләндер талашалар, кем беләндер ярашалар, беркем ышанмаган планнар коралар, беркем аңламаган карарлар кабул итәләр... Ә патшаларның ни кылганын бөтен кеше дә аңларга тиеш түгел, югыйсә бөтенесе дә: «Мин дә патша була алам икән», – дип уйларга мөмкин.

Гомер буена кешенең алдында бер генә сорау тора. Төрле баскычларда ул үзенә шул сорауны куя, җавап бирә һәм шуңа башкаларны да ышандырырга тырыша. Ә беренче карашка ул сорау бик гади яңгырый: кем син?

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Күпме гомер бирәләр бит

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Казанда гел кереп йөри торган бер автосервисым бар. Машинам төзек булганда да кереп чыккалыйм мин анда. Сервис хуҗасы Владимир Кузнецов белән сөйләшеп утыру – үзе бер гомер. Шактый зур урыннарда утырган җитәкче, бик мәгълүматлы кеше ул. «Чи урыс» булса да, татарчасы менә дигән, хатыны да татар, Җәвидә исемле. Владимир Александрович аның исемен бер дә бозмыйча матур итеп саф татарча әйтә.

Бер сөйләшеп утырганда, гомер буе бердәнбер хатыныбыз белән яшәвебезгә куаныштык та аннан машина гомере турында сүз кузгаттык. Әңгәмәдәшем әйтүенчә, хәзер машиналарны кыска гомерле итеп ясыйлар. Чөнки җитештерүчеләр күбрәк акча эшләүне беренче урынга куя, сыйфат мәсьәләсе арткарак күчеп тора икән. Ягъни машина тиз ватылса, яңаларын сатып алучылар күбәя, ихтыяҗ җитештерүне дә арттыра. Әле моңа запас частьлар мәсьәләсен дә өстәргә кирәк, бит машина озак еллар ватылмый йөрсә, запчастьлар, аларның аналогларын җитештерүчеләр һәм сатучылар авыр хәлдә калачак. Тагын шунысы кызык: кибеткә кергәч, сатучы синнән: «Оригинал кирәкме, аналогмы?» – дип сорый. Запчастьның оригиналын аласың инде, озакка чыдар дип өметләнәсең. Әмма аның оригиналы белән шуңа охшатып ясалганын ничек аерасың ди инде, җә! Шул сатучы намусына гына ышанырга кала. Владимир Александрович әйтүенчә, кайбер запчастьларга, мәсәлән, Кытайда эшләнгәннәренә хәтта гарантия дә бирмиләр икән. Кытайларны эшли белмиләр диясе килми.

Алар: «Бездә бөтен нәрсә югары сыйфатлы итеп эшләнә. «Китайский ширпотреб» дип әйткәннәре – бракка чыгарылганнары һәм алар монда сатылмый. Россия алыпсатарлары аларны арзан бәягә ала да сезгә кыйбатка бирә», – дип аңлатканнар иде. Тикшереп карамагач, гөнаһысына керәсе килми, әмма сәүдәдә сыйфатсыз тауарларның ишәюе дә хак.

Күптән түгел микродулкынлы мичебез ватылды. Оста чакырттык, мичнең төп детале – магнетрон эштән чыккан икән, оста аны югары ешлыктагы нурланыш бирә торган электрон лампа дип аңлатты. Яңаны алып килеп куйды бу, әмма мичтә «җылы» дигән сүзнең «җ» хәрефе дә юк. Егетебез: «Ярый әле гарантия белән бирделәр», – дип, шул лампаны алыштырып кайтты. Шөкер, мичкә җылы «йөгерде». Шатланып яши генә башлаган идек, мич тагын ватылды. Остага шалтыраттым, килде бу, бәхеткә, электрон лампага пычак та булмаган. Әмма икенчесенең, арзанрак торса да, бер хикмәте бар икән. Яңа микродулкынлы мичләрдә ул тагын бер-ике деталь белән бергә аерым бер саркофаг эченә куела һәм аны ачып булмый ди, димәк, шул берничә детальнең берсе эштән чыкса да, син шул саркофагны сатып алырга тиеш буласың, ә ул кыйбат тора. Оста егет әйтүенчә, ул күбрәк акча эшләү өчен махсус шулай ясала. Ярый әле безнең мич иске, егет әйтүенчә, «добротный» эшләнгән. Ә яңалары күп дигәндә ике елга чыдый икән. Аннан соң хет чыгарып ат!

Инде менә кирәкле детальне тапса ярар иде, дип, теләкләр тели-тели, останы көтеп утырам. Чөнки ул, хәзер запчастьлар табу кыен, заказ биреп кайтарырга туры килмәгә, дип куркыткан иде.

Заманында «сыйфат бишбеллыклары», шәхси келәймә белән тауар чыгарулар бар иде, шуңа күрә сыйфат өчен, сатып алган әйбернең гомерле булу-булмавы өчен борчылмадык. Вәт бит заманалар!

АГУНЫҢ НИК ДӘВАСЫ ЮК?

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Соңгы көннәрдә мошенникларның югары чиновниклар, эре компанияләр җитәкчеләрен, профессорлар һәм академикларны төп башына утыртулары ешайды. Аңлашыла: караклык юлына бик яхшы мәгълүматлы, югары технологияләр белән коралланган, кеше психикасының нечкә якларын яхшы белгән затлар баса һәм максатларына ирешәләр дә.

Миллионлаган һәм йөз миллионлаган сум акча җиңел генә караклар хисабына күчә. Аларның корбаннары – чүп кешеләр түгел, кайсыдыр бер тармакта ат уйнаткан, зур эшләр майтарган шәхесләр. Һәм менә шулар бакча баласы кебек җиңел генә алдана да куя. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов: «Телефоннарыгызны карабрак йөрегез, егетләр!» – дип мөрәҗәгать иткәндә, мәктәп балаларына түгел, ә министрларга һәм ведомство җитәкчеләренә эндәшә бит.

Россиякүләм соңгы хәбәрләрдән берничә очракны карап үтик. Екатеринбург администрациясе чиновнигы мошенникларга миллион сум акча күчергән. Җитмәсә ул Милек белән идарә итү департаменты җитәкчесе урынбасары икән, ягъни кәгазь тутырып утыручы гади бюрократ кына түгел. Аңа телефоннан башта «җитәкче»се шалтыраткан һәм бик мөһим эш белән ФСБдан элемтәгә керәчәкләрен әйткән. «ФСБ» озак көттермәгән: шалтыратып, мошенникларның аның исеменә 7 миллион сум кредит алуларын һәм украин сугышчыларына күчерергә җыенуларын хәбәр иткән. Моны икенче бер кредит алып, «куркынычсыз хисап»ка күчереп кенә туктатып була икән. Бик беркатлы схема инде, килешәсездер. Әмма шул схемага бар корбаннар да бик җиңел каба. Чиновник сөйләшүне хезмәттәшләреннән яшереп, банкка чапкан, банкта аңа берсүзсез 1,1 миллион сум кредит рәсмиләштергәннәр һәм «куркынычсыз хисап»ка акча күчерелгән дә.

Очучы-космонавт Михаил Тюрин 15–20 декабрь аралыгында мошенниклар белән элемтәдә торып, 10 миллион сумны шундый ук схема белән караклар хисабына күчереп куйган. 2001 елда Халыкара космик станциядә 128 тәүлеклек очыш ясарга һәм фәнни экспериментлар үткәрүдә катнашырга башы җиткән Россия Героеның мошенниклар кармагына капмаслык акылы табылмаган.

Россия Фәннәр академиясенең галим-юристы Лев Клебанов телефон каракларына 6,6 миллион сум күчергән. Ул банк серен бозуларга каршы системалар ясаучы булган, ягъни мошенниклардан безне сакларга тиешле адәм баласы. Кем-кем, менә ул мошенникларның кәкре каенга терәтү ысулларын яхшы белергә тиеш иде. «Телеграм»нан ул үзен мәгариф һәм фән министры урынбасары эзли дигән хәбәр алган. Галим урынбасарның кабул итү бүлмәсенә шалтыраткан һәм аңа түрәнең киңәшмәдә булуын әйткәннәр һәм көтеп торырга кушканнар. Бераздан телефон шалтыраган һәм министр урынбасары роленә кергән мошенниклар тапталган схема буенча корбанны эшкәртергә тотынган. Мондыйрак сюжет уйлап чыгарылган: украин хакерлары министрлык сайтын ватканнар һәм галимнәр исеменә кредитлар рәсмиләштерә башлаганнар. Клебанов исеменә дә кредит алынган. Мошенниклар тагын Росфинмониторинг һәм ФСБ хезмәткәрләре роленә дә кереп сөйләшүләр алып барган. Әңгәмә «куркынычсыз хисап»ка 6 миллион 602 мең сум акча күчерү белән тәмамланган.

«Газпромнефть»нең топ-менеджеры һәм Росприроднадзорның фәнни-техник советы җаваплы секретаре Игорь Гершанович 40 миллион сум акчасын «куркынычсыз хисап»ка күчергән. Акчасы беткәч, аны квартирасын сатарга күндергәннәр. Соңыннан аңа кабергә куела торган венок җибәргәннәр, чәчәкләр арасына гаиләсенә һәм үзенә янау сүзләре язылган кәгазь дә кыстырганнар.

Болар – соңгы көннәрнең һәм атналарның хәбәрләре арасыннан чүпләнгән яңалыклар гына. Барысы да түгел. Алданган интеллектуаллар һәм чиновниклар саны яңгырдан соң чыккан гөмбәләр тизлеге белән үсә. Монда инде кешеләрне наданлыкта, баш мие булмауда гаепләп булмый. Башлары эшләмәсә, алар карьера баскычыннан алай җиңел югарыга күтәрелә алмаслар иде.

Бу юллар авторын башка мәсьәлә борчый: кешеләр ничек бик җиңел кармакка каба? Балык та бит җиме булмган кармакка якын килми. Телефоннан бөтенләй шәрә кармак ташлана һәм зур эшләр майтарып, массалар белән идарә итүче бик күпләр шуны йоталар да куялар. Югыйсә мәгълүмат кырына көн саен мошенниклар схемасы хакында хәбәрләр чыгып тора, башкаларның нәкъ шул ысуллар белән алданулары турында дистәләгән чын сюжет ишетәбез. Әйтик, фатирны сатырганда: «Ышаныч язуы белән фатирыңны сатарга җыеналар, алардан алда үзең сатып кал», – диләр. Ярый, шулай булсын, ди. Беренче карашка андый хәл булырга мөмкин шикелле тоела. Әмма күчемсез милке булган һәр кеше белергә тиеш: нотариустан башка гына ышаныч язуы белән фатир сатып булмый. Инде кемдер синең фатирны сатарга җыена икән, аны уза алуың икеле, иң яхшысы хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итү. Аннан соң фатир саткан акчаны кемдер күрсәткән хисапка күчерү чиктән ашкан наивлык бит инде. Бер гади авыл тракторчысын яисә сыер савучыны шулай алдасыннар да ди, монда бит үзен җәмгыятьнең каймагы-элитасы дип санаганнарны төп башына ике дә уйламый утырталар.

Мошенникларның чиста суга чыгарылмаулары, кара эшләрен бик актив давам иттерүләре үзе бик күп сораулар уята. Мәсьәләнең ул ягын күтәрмим әле мин. Караклар үз корбаннарының кем икәнен бик яхшы белеп эш итә бит күпчелек очракта. Димәк, аларның кыек эшләреннән дә хәбәрдар. Проблеманың бу ягына да кагылмыйк.

Ни өчен акыллы гына кешеләр бик җиңел телефон гипнозына бирелә? Сорауның шунысы борчый әлегә. Ниндидер технология бар икән, аны эшләүче белгечләр төркеме дә бар. Аңа каршы технология, ягъни медицина термины белән әйтсәк, «вакцина»сы да булырга тиеш. Безнең психологлар, психиатрлар, мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча белгечләрнең бюджеттан хезмәт хакы алучы йөз меңләгән армиясе кайда һәм ни эшли? «Уяу булыйк!» – дип кенә әллә ни майтарып булмый монда. Күреп торабыз бит: сак булырга өйрәтеп матбугатта язу-сөйләүләр генә тиешле нәтиҗә бирми. Кеше телефонны алдымы, гипнозлана. Кем генә булмасын, ихтыярсыз колга әверелә. Шуны раслау өчен югарыдагы мисалларны китердем дә инде мин. Моңа каршы антидот кайда?

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ҖЫЛЫНУ

ШӘЛЧЕЛӘР ҺӘМ ИТЕКЧЕЛӘР ӨЧЕН ЕЛ УҢЫШЛЫ КИЛДЕ

Быелгы карлы кыш онытыла төшкән киез итекләргә дә, кабарып торган мамык шәлләргә дә игътибарны арттырды шикелле. Шәлчеләре һәм итекчеләре белән дан казанган авыллар халкы да безнең фикерне раслады.

Балык Бистәсе

40 елга җитә

Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылына чыгуыбыз юкка гына түгел, чөнки биредә һәр хатын-кыз, буш вакыты булган саен, кулына инә белән җеп ала. Авылда иң оста һәм өлкән бәйләүчеләрнең берсе Сания Әхмәтҗанова әйтүенчә, ул шәл бәйләргә 6 яшендә үк әнисеннән өйрәнгән. Шуннан бирле кулыннан инә белән җебе төшмәгән. Заманында аялаган да, эрләгән дә ул.

– Ул заманнарда аның файдасы да бар иде. 2000 нче елларга кадәр шәл бәйләп сатып, шактый мантып калып булгандыр. Хәзер файдасыннан бигрәк хезмәте күбрәк. Җиңел эш түгел, аның өчен саулыкның яхшы булуы кирәк. Гел шул эш белән генә утырсаң, бер косынканы 3–4 көн эчендә дә бәйләп чыгарга мөмкин, ләкин минем андый вакытым юк. Элеккеге еллардагы кебек күпләп бәйләмәсәм дә, буш та утырганым юк, – ди оста.

Шәл бәйләү исә мамык сайлаудан башлана. Анысын да бик белеп башкарырга кирәк икән.

– Мамыкның озын булуы әйбәт. Эш күңел җылысын биреп, бисмилләһне әйтеп, үземә дә, алган кешегә дә файдасы булсын, дип матур теләкләр теләүдән башлана. Шуннан соң мамыкны җиренә җиткереп эшкәртә белергә кирәк. Шәп итеп юабыз, чайкыйбыз һәм киптерәбез, тетәбез, шапылдатабыз, җепләр кушып эрлибез. Шәлнең җылысы 30–40 елга кадәр җитә. Хатын-кызның чын, табигый материалдан эшләнгән бер шәле булса, ул аның аркасын да җылыта, авыруын да дәвалый. Ятып торса да, утырып эшен эшләсә дә, шәлен аркасына салса, шифасын, җылысын ала. Балаларны мунчадан төреп чыгарга кирәк, дип тә сорап алучылар булды, – ди Сания апа.

Сораучылар да күп икән. Элек ул күз нурын түгеп бәйләгән шәлләрен сатарга базарга йөрсә, хәзер заказларны телефоннан кабул итә дә почта аша җибәрә яки кешеләр үзләре килеп ала.

– Узган ел Башкортстаннан да сорадылар. Аларга да шәлләр, жилетлар бәйләп җибәрдем. Шәлләрем Мәскәүгә, Төркиягә кадәр барып җитте инде. Бу кышта башкаларына караганда күбрәк саттым дип әйтә алмыйм. Гадәтенчә, – диде шәл бәйләүче оста.

Күгәрчен авылы хатын-кызлары шәл бәйләү белән танылсалар да, хәзер муенлы кофта, свитер, жилетларга кадәр бәйләп саталар икән. Оекбаш, бияләй, шарфлар турында әйтеп тә торган юк.

– Быел заказларым бик күп булды, – ди Гөлфирә Калиева. – Әле тагын да күбрәк бәйләр идем, төп эштән бушап булмый. Ә бәйлисе килә, чөнки ул безнең канга сеңгән. Әбиләр, әниләрнең кулыннан энә-җеп төшмәде. Үзебез дә – 4–5 яшьтән үк кул арасына кереп үскән буын без. Җанга да тынычлык бирә, файдасын да күрәбез. Яшүсмер чорда шәл бәйләргә төштән соң – беребезгә, кичен икенчебезгә җыела торган идек. Ә җәйләрен капка төпләре тутырып утырыр идек. Элек бездә һәр капка төбендә 2–3 хатын-кыз җыелышып, гел бәйләп утырышлы иде. Хәзер кимеде дисәк тә, капка төбендә шәл бәйләп утыручылар әле дә бар.

Шәл бәйләр өчен кәҗәнең сыртындагы яхшы мамыклары гына тотыла, калганнарыннан оекбаш, бияләй бәйлиләр. Мамыкны исә Волгоград якларыннан алып килеп саталар.

– Шәл гел сорыйлар иде, ә бу кышта тагы да артты. Бәйләгән кешеләрнең товары тормый, һәрберсе сатылып бара. Быелтыр бездә узган «Бистә шәле» фестиваленнән соң тагын да күбрәк сорыйлар. Күрәләр, беләләр. Бәйләп өлгертергә генә кирәк. Башта без бары тик шәл генә бәйләдек, аннан соң сораучылар арткач, оекбаш, бияләйгә керештек. Өчпочмаклы косынкалар, кофта, жилетлар сорый башладылар. Менә быел ак шәл (паутинка) модага керде. Кыскасы, яңарыш, үзгәреш гел булып кына тора, – ди ул.

Күгәрчен авылы апалары әйтүенчә, моңа кадәр шәлнең бәясе арзан булган. Быел кыш күтәрелгән, чөнки мамыкның бәясе арткан.

– Бер яхшы шәл бәйләр өчен 400 грамм мамык кирәк. Берничә ел элек аны 600–700 сумга ала идек, бүген ул 1600–1800 сум тора. Быел 2000 сумга кадәр менә, диләр. Шуңа күрә бу сезонда шәлне – 4–5 меңгә, косынкаларны 2000–2500 сумга, паутинка сыманнарын 3000–3500 сумга сатабыз, – диде алар.

Кукмара

Итек суык ярата

Кукмара районының Туембаш авылы исә итекчеләре белән данлыклы. Биредә яшәүчеләрнең күпчелеге итек басып көн итә. Без шул осталарның берсе Рамил Галимов белән аралаштык. Элегрәк ул итекне әтисе белән бергәләп басса, хәзер, төп эшеннән бушаган арада, үзе генә эшли.

– Итек суык ярата. Суык булса, кеше – итек, җылы булса, суыткыч ала, диләр. Декабрь башы бик җылы булды бит. Аңа кадәр итекне яхшы алдылар. Яңгыр яугач, сату тукталды. Итекне мин ел әйләнәсе басам. Бер көнгә 3–4 пар итек, сыйфатлы итек әзерлим. Бер пар итекне әзерләргә 7–8 сәгать вакыт кирәк. Эшләгән бере сатылып бетеп бара. Безнең авылда итек басучылар күп, кемнең ничектер, тик миннән, узган ел белән чагыштырганда, азрак алалар. Моңа кышның соң килүе дә, башында яңгыр яву да сәбәпчедер дип уйлыйм. Ләкин елына күрә сату әйбәт, зарланып булмый. Моннан да начаррак сатылган вакытлар булды. 2010 елның кышы бик салкын килде, менә шул елны итекнең мичтән төшкәнен көтеп торалар иде. Гомумән, итекне сатып алучылар да, басучылар да елдан-ел кимидер, дип уйлыйм. Чөнки итекне башлыча авылда кияләр, ә алар бетүгә таба бара, – ди ул.

Рамил әйтүенчә, халык әйбәт итек йомшак була дип уйлап ялгыша. Яхшы итек каты була, ди.

– Йомшагы җайлы, тик тиз тарала торган була. Ә каты итек үз формасын озак еллар югалтмый. Аннан соң итекнең уңышлы булуы йоннан да тора. Итек өчен көзге йон кирәк. Элек аны үзем күрше-тирә районнардан җыя идем. Хәзер китереп саталар. Башта йонны тигәнәкләрдән чистартабыз, аннан соң тетүчеләрдән теттерәбез. Авылда андый егетләребез дә бар, – ди оста.

Итек үз хуҗасына озак вакыт хезмәт итсен өчен, берничә киңәшен дә бирде.

– Йөреп кайткач, итекнең карын себерергә, киптерергә кирәк. Кайнар урынга куярга ярамый, юеш табан ката һәм итек утырачак. Җепшек көнне итек утыра, кечерәя. Пычранса, юарга ярамый. Кипкәнен кагарга, аннан щетка белән чистартырга кирәк. Кара итек бераз ялтырап торсын өчен, көнбагыш мае белән майлау яхшы, – ди Рамил Галимов.

Зур Кукмара авылында яшәүче Рәмзия Галимҗанова исә: «Быел итекне басып җиткереп булмый», – ди.

– Безнең басучыларыбыз да, түшәүчеләребез дә бар. Шуңа күрә күпләп һәм ел әйләнәсе эшлибез. Җәен көненә 4–6 пар итек бассак, кышын 10–11 кигә җитә. Бер пар итекне 1400 сумнан саттык. Баскан бере сатылып бара. Быел хәтта декабрь башындагы яңгырлар вакытында да саттык аны. Октябрь ахыры – ноябрь башында катырган булса, тагын да шәп буласы иде. Мәскәүдән дә, Санкт-Петербург, Екатеринбургтан да күпләп алып китәләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәл сайлыйбыз

Яхшы шәл йомшак, нәфис, ялтырап тора торган була. Әйбәт шәл алган вакытта ук мамыклы булмаска да мөмкин, чөнки бөтен кеше дә мамыклы итеп бәйли алмый. Шуңа күрә мамыгы чыкканлыкка карап кына алмаска киңәш ителә. Элек хатын-кызлар шәлнең калынлыгын, җылылыгын карасалар, хәзер нәфислеге һәм матурлыгына игътибар итәләр, ди осталар. Тыгыз бәйләнгән шәлләр озаккарак чыдый, буш бәйләнсә, тиз коела. Шәл яба-яба кабара, моның өчен махсус берни дә эшләргә кирәкми.

Итек сайлыйбыз

Яхшы итеп басылган итек, көн саен киеп йөрсәң дә, 3–4 елга җитә. Чын итекнең асты калын, үзе нык, тыгыз була. Башын бөкләгәч, шарт итеп кире атарга тиеш ул. Итекнең уңы, сулы юк. Аякка кигәч, үз формасын ала. Җылылыкка килгәндә, буялмаганы җылырак.

Сәрия МИФТАХОВА

КЫШ КӘЕФЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Дула, буран!

Бу бураннар буранмыни, элек айлар буе дулаган әнә. Зәй шәһәрендә яшәүче 87 яшьлек Рифкать абый Шәвәлиев 70 елга якын һава торышы буенча күзәтүләр алып бара. Заманасында агроном булган, җитәкче урыннарда эшләгән. Үз гомерендә кышларның да, җәйләрнең дә ниндиен генә күрмәгән. «Дәфтәргә язып кую кирәкми, минем башым үзе – компьютер», – дип шаккатырды ул безне.

– Без кечкенә чакта бураннар лапас, кечкенә өйләрне каплый иде. Иртән ялгыз карчыкларны казып чыгара идек, – ди Рифкать ага. – 1969 елда кышның өч ае да суык булды. Авыл хуҗалыгына авырга туры килде. Фермаларда, йортларда торбалар катты. Җәй кызулыгы, корылыгы белән интектерде. 1978 елның 31 декабрендә исә температура –52 градуска кадәр төште. Газ торбалары шартлап, хәтта Зәй ГРЭСы эшләми башлады. 1971 ел да үзенчәлекле килде: августта ява башлаган яңгырлар 7 декабрьгә кадәр сузылды. Комбайннар басуларга керә алмады. Декабрь башында гына туңдыра башлады. 1972 елның язы исә иртә килде. Беренче яңгыр 1 августта тамчылап кына яуды. Чәчкән әйберләрнең берсе дә тишелмәде, бәрәңге уңышы булмады. Бәрәңгене Польшадан кайттарттылар. Колорадо коңгызының кайткан елы инде бу.

Рифкать бабай әйтүенчә, хәзер сынамышларга карап, алда нәрсә буласын төгәл генә әйтеп булмый. Моны ул табигатьнең үзгәрүенә бәйләп аңлата. Төньякта бозлар эрү, океаннар җылыну, Гольфстрим агымнары үзгәрү һава торышын бик нык бутап бетергән. Элек җылы булган җирдә салкыннар булгалый. «Әгәр кышкы суыклар күпкә китсә, җәйнең эссе, коры килүе дә бар», – дип фаразлый ул. Ә кар яву – файдага гына.

Хут суыкларын көтәбез

Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче Рәис Шәкүров та балачагын искә төшереп алды.

– Нәкъ безнең балачак бураннары бу. Кечкенә чакта әти лапаска фонарь тотып чыга иде. Ул вакытта электр юк. Өй белән абзар арасы – 10 метр. Шушы ике арада йөргәндә дә, давыл фонарь утын сүндерә иде. Бүген балачагымны искә төшереп, буран эчләрендә йөрдем әле. 4–5 ел инде юньле буран күргән юк иде. Кар бит ул – икмәк. Яусын, кыш карлы булырга тиеш. Тик шул ягы гына борчый: явым-төшем артыкка китсә, җәен давыллар, су басуларга китерергә мөмкин, – ди Рәис Шәкүров.

Халык синоптигы искәртүенчә, бураннардан соң салкыннар башлана. Алда хут суыклары (19 февральдән 19 мартка кадәр) бар. Ул суыклар кирәк. Бу очракта җәй бик яхшы киләчәк. Быелгы җәй матур килер: яңгыры да вакытында явар, җиле дә вакытында исәр, дип фаразлый ул. Икмәк булса, ит тә, сөт тә булыр.

– Элек айлар буе суык була иде, хәзер һава торышы бозылып бетте. Газ ягып, өйне җылытабыз, тәрәзә ачып суытабыз. Шуңа да бәйле ул. Табигать җылынуга таба бара. Ноябрь аенда минем бакча сукалаган юк иде әле, быел сукаладым. Гадәттә ноябрьдә кеше малларын суеп бетерә иде, хәзер декабрьсез суймый. Хәзер хикмәтләр күп, – ди Рәис Шәкүров.

2024 ел, 17 гыйнвар. Мамадыш районының Бөрсет Сукачы авылы.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар УСМАНОВ,
Чүпрәле районының Иске Чәке авылы агрономы:

– Кар яугач, җирдә дым була, дип сөенәбез генә. Авыл хуҗалыгы өчен файдасы зур. Бүген кырларда уртача кар катламы 35–40 сантиметрны тәшкил итә. Ул 1–2 метрга җитсә дә, куркыныч түгел.

Уҗымнар кар белән томаланган, алар җылыда саклана. Декабрь башында яңгыр явып, кар бөтенләй эреп бетсә дә, боз катламы барлыкка килмәде. Узган кыш исә 2–3 басудагы бозны ваттырырга туры килде. Җәйне Аллаһтан узып фаразлап булмый. Табигать шартларының нинди булуына карамастан, без, тырышып эшләп, җирдән уңыш алырга тиеш.

Сынамышлар

➤ Чыпчыклар кыш көне бер урынга җыелышып чыркылдашсалар, җылы булып кар явар.

➤ Эт карда аунаса, көн аяз булыр.

➤ Каз аягын күтәреп торса, салкын була.

➤ Гыйнварда кар күп яуса, бураннар еш булса, җәй яңгырлы килер.

➤ Утын сызгырса, көн суытыр.

➤ Кыш көне бәс күп булса, агач җимешләре уңар, бал күп булыр.

➤ Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.

➤ Сукыр тычкан оясыннан гыйнварда чыкса, май салкын булыр.

Кач мануда ник җылы?

Бүген – Кач ману көне. Раштуада салкын булды, ә менә христиан динендәгеләр бәкегә чумган вакытта була торган зәмһәрир суыклар кая киткән? Моның серен КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология, климатология һәм экология кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцевтан сорадык. Сәбәбе Төньяк Атлантикадан килүче җылы циклонга бәйле икән. Шуңа күрә суыклар чигенгән дә инде. Җылы көннәрдә җепшек һава торышы да булырга мөмкин.

Белгеч әйтүенчә, хәзерге вакытта кар катламының биеклеге 50 сантиметрга җиткән. Бу инде – февраль нормасы. Җирнең дым запасы өчен бу бик мөһим. Ни өчен дигәндә, җәен июль коры килә, яңгырлар җитми.

– Гыйнвар ае бик салкын булмас. Иң салкыны 1969 елга туры килде. 2010 ел да суыклары белән истә калды. Климатик норма буенча хәзер температура –10 градус тирәсе булачак. Аннан +1 градус күтәлә. Менә шундый тотрыклы булмаган аномаль һава торышы. Мондый көннәрне кайберәүләрнең организмы бик авыр кичерә. Февраль исә җылырак булачак. Онытмагыз: гыйнвар – елның иң салкын ае, – ди Юрий Переведенцев.

Кыш көне яуган явым-төшемгә карап, җәйне яңгырлы, җылы була дип фаразлау дөресме? «Юк, – ди профессор. – Бер вакыйгага, әйтик, Кач ману суыклары булмаганга карап кына, еллык фараз ясап булмый. Атмосфераның хәтере ике атналык. Ул алда нәрсә булганны оныта».

Табиб киңәше

Суфия ШӘРӘФИЕВА,
терапевт:

– Һава торышының еш үзгәреп торуы өлкәннәрдә генә түгел, яшьләрдә дә үзен сиздерә. Җәяүле буран, җил, магнит давыллары организмга бик нык тәэсир итә. Бигрәк тә хатын-кызлар, үсмерләр сизгер. «Хәл юк», «баш авырта», «кан басымым уйный» дип зарланучылар шактый. Йөрәк-кан тамырларында үзгәрешләр булган кешеләргә канны сыеклата торган дару эчеп куярга кирәк.

Сөтләп кара чәй эчегез. Кура җиләге, карлыган, бал белән эчү дә файдалы. Бал тынычландыра. Тирләгәч, организм җиңеләеп китә. Лимонны катырыгыз да шуны ашка, чәйгә кырып салыгыз. Хәл кертү өчен бик әйбәт. С, B_6 төркеменә керүче витаминнарны кулланырга мөмкин. Җылы итеп киенеп йөрергә тырышыгыз. Аяк киеме иркен булсын. Тукталышта автобус көткәндә, басып кына тормагыз, селкенегез. Физкультура ясагыз, күбрәк җәяү йөрергә тырышыгыз.

Кофе эчкәч, ашагач, кар көрәмәгез! Көрәгәндә, тәмәке тартмагыз. Йөрәк-кан тамырлары авырулы кешеләргә кар көрәү киңәш ителми. Бу – авыр эш. Гадәттән тыш хәл булганда, ярдәмгә чакыру өчен, телефонны һәрвакыт кесәгездә йөртегез.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

БУРАНЫ ШУНДЫЙ КӨЧЛЕ

ИШЕП ЯУГАН КАРНЫ КАЙДА ҺӘМ НИЧЕК ҖЫЕШТЫРАЛАР?

Татарстанны атна башында каплаган кар бураны үз җаена баручы тормышны тәмам чыгырдан чыгара язды. М12 автомобиль трассасының республикага туры килгән өлеше туктап калды, федераль һәм төбәк юллары ябылды, аэропорт эше чикләнде, ә Казанда «Буран» операциясе игълан ителде. Табигать тынып, бераз хәл алганнан соң, кабат көчле буран күтәелә. Ишеп яуган карны җыештырып бетерергә көрәк җитәрме?

Табигать сынавы

Быелгы кыш чын мәгънәсендә истә калырлык булды. Яңа ел алдыннан илнең күп кенә төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда яңгыр ишеп яуса, бәйрәм борын өшерлек суыклар алып килде. Ниһаять, җылыта дип тә юкка сөендек, ахры. Салкыннар берешү белән беррәттән, дүшәмбедән илнең үзәк өлешендә көчле бураннар башланды. «Пәнҗешәмбе – бераз ял, аны табигатьнең киләсе һөҗүменә мөмкин кадәр файдаланырга кирәк. Җомгадан республикада өч тәүлек дәвамында кабат күп кар һәм көчле җил көтелә», – дип кисәттеләр бу атнада Татарстанда яшәүчеләрне Министрлар Кабинетында узган киңәшмәдә.

Татарларның гына түгел, юл салучыларның да акылы төштән соң: буран аркасында туктап калганнан соң, М12 автомобиль трассасында кардан саклау өчен коймалар төзергә, юл буена агачлар утыртырга җыенулары билгеле булды. Ә бу атнада анда хәлләр, чыннан да, сөенерлек түгел иде. Каты җил һәм кар көртләре аркасында, юлның Шәледән күрше Чувашиянең Канаш шәһәренә кадәр арасы ябылды, машиналарны кар каплады. Түләүле трассада кар тозагына барлыгы йөзгә якын машина эләккән. «Автодор» дәүләт компаниясе һава торышы начар булган шартларда юлга чыкмаска киңәш итте.

Буран котырган мәлдә федераль һәм төбәк юллары да автобуслар, маршрут таксилары һәм йөк ташучы машиналар өчен ябылып торды.

– Автомобиль йөртүчеләр юл буенда туктап калырга мәҗбүр булу сәбәпле, аларны ашау-эчү һәм ягулык белән тәэмин итүне оештырдык, – диде Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов.

Ишеп яуган кар Казан халыкара аэропорты эшен дә чикләде. Башкалага Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән, Уфа, Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдән килүче очкычлар төшеп утыра алмады.

– Очып китү һәм кайту шул вакыттагы һава торышына карап башкарыла. Әлеге карарны экипаж командиры кабул итә, – диде Казан аэропортының матбугат хезмәте җитәкчесе Гадел Гатауллин.

«Буран»лы Казан

Буранлы Казанда «бөке»ләр ун баллга җитте. Җир астында да мәхшәр: метрода халыкның күплегеннән өстәмә вагоннар җибәрергә мәҗбүр булдылар. Шәһәрдә «Буран» операциясе игълан ителде. Бер тәүлек эчендә генә дә башкала урамнарыннан 12 мең тоннадан күбрәк кар чыгарганнар. 16 гыйнвардан 17 гыйнварга каршы төндә шәһәр урамнарын чистартырга 800гә якын техника чыккан.

– Юл хезмәтләре тәүлек әйләнәсе көчәйтелгән режимда эшли, – диде Казан Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты җитәкчесе урынбасары Марсель Әхмәтҗанов. – Көндез урамнарны 674 кеше кардан чистарта. Эш туктап тормасын өчен, аларга ашарга да шунда ук алып киләләр.

Сүз уңаеннан, башкалада тәртиптә тотарга кирәкле юлларның гомуми мәйданы 22 миллион квадрат метр тәшкил итә. Карны сигез кар эретү станциясенә озаталар. Бирегә тәүлегенә 8 мең тоннага кадәр кар кабул итә алалар. «Кыш башланганнан бирле кар эретү станцияләренә 400 мең тоннага якын кар китергәннәр», – дип хәбәр иттеләр Казан мэриясенең матбугат хезмәтеннән.

Карга чумган ишегалларын җыештырырга 1,5 меңгә якын урам себерүче чыккан.

Башкаладагы хуҗалык кирәк-яраклары сатучы кибетләрнең берсендә эшләүче Марат Сафин сүзләренә караганда, буранлы бер көндә кибеттәге бөтен көрәкләрне сатып бетергәннәр. Рекламадагы кебек тәгәрмәч астында калса да сынмый торган 9 мең сумлык пластмасса көрәкләрдән дә җилләр искән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авылның – үз эше

Шәһәр халкыннан аермалы буларак, авылда яшәүчеләр алдан аяк киенә.

– Кар, буран буенча авыл җирендә тәҗрибә зур, – ди, елмаеп, Актаныш районының Иске Айман авыл җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтханов. – Олы кешеләр белән киңәшеп, үзара салым акчасының билгеле бер өлешен алдан ук урамнарны кардан чистартуга калдырабыз. Оешмалар белән килешүләр төзелгән, аларның техникасы ярдәмендә урамнарны тәртиптә тотабыз. Бүгенгә кадәр бу мәсьәләдә бернинди дә өзеклелек булганы юк. Безнең җирлеккә өч авыл керә. Аларның берсе – унга якын хуҗалыклы Чиялек авылы. Үзәктән җиде чакрымлап ераклыкта урнашкан ул. Кечкенә генә сала булса да, юлны даими ачып торырга кирәк. Чиялеккә атнага бер кибет килә. Мегаполиста нинди шартлар булса, кечкенә авылда яшәүчеләргә дә шулар ук кирәк бит. Алар да шул ук һаваны сулый, шул ук юлдан йөри. Кеше аз дип, кечкенә авыл халкы карга чумып ятарга тиеш түгел.

Нурлат районының Иске Әлмәт авыл җирлегендә яшәүчеләрнең дә буранга артык исе китми. Узган көздә яңа трактор сатып алган алар.

– Безнең 1,5 миллион сум грант акчасы бар иде. Шуңа халык белән килешеп, үзара салым акчасын өстәдек тә МТЗ-82 тракторы сатып алдык. Менә сөенеп туя алмыйбыз хәзер, – ди җирле үзидарә башлыгы Равил Хисамов. – Явым-төшемнәр башлануга, трактор гел йөреп тора. Иске Әлмәт һәм Яңа Әлмәткә 28 чакрым юл керә. Шактый ара булса да, борчылысы юк, трактор тиз йөри, авыл урамнарын хәзер ялт иттерә. Техникада Нияз Кәримов исемле уңган егетебез эшли. Бу эш бездә тулысынча җайга салынган, кар яуса да куркытмый.

ЧИСТАЛЫК ӨЧЕН КЕМ ҖАВАПЛЫ?

Территория	Җаваплы
Җирле әһәмияттәге юл	Җирле үзидарә яллаган подрядчы оешма
Күпфатирлы йорт ишегалды	ТСЖ, идарәче компанияләр
Төбәк әһәмиятендәге юл	Төбәктәге юл хуҗалыгы эшчеләре
Федераль юл	«Росавтодор» федераль юл агентлыгы
М12 автомобиль трассасы	«Автодор» дәүләт компаниясе

Белеп торыгыз!

ИШЕГАЛДЫН ЧИСТАРТМАСАЛАР...

Хокук белгече Диана ГӘРӘЕВА:

– Күпкатлы йорт яны территориясен җыештыру өчен идарә итүче оешма (идарәче компания, төзүче компания (застройщик), ТСЖ) җаваплы. Россия Хөкүмәтенең махсус карары нигезендә елның һәр фасылы өчен мәҗбүри минималь эш күләме дә расланган. Салкын көннәрдә коммуналь хезмәткәрләр люк капкачларын һәм янгын гидрантларын, ишегалдындагы юлларны, мәйданчыкларны һәм машина кую урыннарын кардан чистартырга; кар булмаган территорияне себерергә; йорт яны территориясен боздан арындырырга; юлларга ком һәм тоз катнашмасы сибәргә; түбәдән салынып торган бозны бәреп төшерергә тиеш.

Әлеге эшләр башкарылмаса, бигрәк тә кардан чистартмасалар, турыдан-туры идарә итүче оешмага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Казанда, мәсәлән, шикаятьләрне «Открытая Казань», «Народный контроль» порталлары аша җиткерергә яки **(843) 236-41-23 (диспетчер хезмәте), (843) 223-19-22 (ТКХ комитеты)** телефон номерлары буенча шалтыратып хәбәр итәргә дә мөмкин.

КАР КӨРТЕ МАШИНАГА ЗЫЯН КИТЕРСӘ...

Автоюрист Рафил ХУҖИН:

– Чистартылмаган юлдан тиешле тизлекне саклап барганда, кар көртенә бәрелеп, машинага зыян килсә, бу хакта Дәүләт автоинспекциясенә хәбәр итәргә кирәк. Чөнки әлеге очрак юл-транспорт һәлакәте булып санала. Әлеге юл өчен кем җаваплы булуын да ачыклагыз. Автомобиль юлларын юл хуҗалыгы оешмалары чистартып торырга тиеш булса, ишегалды территориясе идарә итүче оешмага карый. Матди зыянны белү өчен экспертиза үткәргәннән соң, барлык документларны җыеп, судка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә машинага түбәдән кар яки боз төшсә, КАСКО полисы әлеге зыянны тулысынча каплый. Андый документыгыз юк икән, участок полиция хезмәткәрен чакыртырга туры киләчәк.

ЯРДӘМ ИТӘЛӘР

Айрат СӘМИГУЛЛИН, Татарстан Дәүләт автоинспекциясе идарәсе җитәкчесе урынбасары:

– Татарстан Дәүләт автоинспекциясе идарәсе һәлакәткә эләгүчеләргә генә түгел, юлда кыен хәлдә калучыларга да ярдәм итәргә әзер. Моның өчен **5-333-888** һәм **112** телефон номерлары буенча дәүләт автоинспекциясенең дежур бүлекчәсенә шалтыратырга кирәк. Транспорт чарасына бәйле кыенлыклар килеп чыкса, **91-91-91** телефон номеры буенча Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына да хәбәр итәргә мөмкин. Бу атнада Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре юлда кар тозагына эләгүчеләргә 300дән артык «коры паек» өләште. 15–17 гыйнварда республика юлларында 8 кешенең гомере өзелгән.

22 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
006.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16 +
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем...» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
01.45 «Таяну ноктасы» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12 +
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «БОЛЬШОЙ ДОМ» 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.55 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.35, 03.55 Новости 0+
07.05, 21.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25, 00.20 Еврофутбол 6+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
15.00 «Что за спорт?» 12+
15.30 «Громко»
16.30 Смешанные единоборства. UFC. Ш. Стрикланд – Д. Дю Плесси. А. Аллен – М. Евлоев 16+
17.40 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Гомель» (Белоруссия) – «Зенит» (Россия)
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Минск)
22.40 Смешанные единоборства. UFC. В. Шевченко – Д. Ай. П. Ян – Д. Ривера 16+
01.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России. Спринт
04.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Вердер» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
00.45 «ЧОКНУТЫЕ» 0+
02.30 «СОЛО ДЛЯ ПИСТОЛЕТА С ОРКЕСТРОМ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.35, 06.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.10 «Давай разведёмся!» 16+
08.10 «Тест на отцовство» 16+
10.25, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.35 «Порча» 16+
12.45, 01.30 «Знахарка» 16+
13.20, 01.55 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «ВЕСНА СВЕЛА НАС С УМА» 16+
19.00 «СОЛОВЕЙКА» 16+
02.50 «ПРОВИНЦИАЛКА» 16+
05.45 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
05.45 «Герой 115» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ОСТРОВ СОКРОВИЩ» 12+
12.10, 19.55 «По горячим следам» 16+
12.25, 02.35 «ОХОТА НА БЕРИЮ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА» 12+
00.55 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+

23 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Җырлыйк әле!» 12+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 04.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «БОЛЬШОЙ ДОМ» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Что за спорт?» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.35, 03.55 Новости
07.05, 15.00, 18.55, 21.45, 00.45 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Профессиональный бокс. В. Жиров – Д. Тони. Бой за титул чемпиона мира по версии IBF 16+
13.00 «Есть тема!»
15.40 Баскетбол. «Матч звёзд АСБ-2024». Мужчины
17.40 «Короли. Из гетто к победе и золоту» 12+
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – «Спартак» (Москва)
22.40 Футбол. Кубок португальской лиги. Финал 4-х. 1/2 финала. «Брага» – «Спортинг»
01.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России. Масс-старт 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Нова» (Новокуйбышевск) 6+

НТВ
04.45 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
00.55 «СОЛО ДЛЯ ПИСТОЛЕТА С ОРКЕСТРОМ» 16+
03.15 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.15 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.25 «Знахарка» 16+
13.30, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ЗА КАМЕННОЙ СТЕНОЙ» 16+
19.00 «БЫВШИЕ ЛЮБИМЫЕ» 16+
02.45 «ПРОВИНЦИАЛКА» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.00 «ОСТРОВ СОКРОВИЩ» 12+
12.25, 03.20 «ОХОТА НА БЕРИЮ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «Битва оружейников» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

КУЕРУ МИХНӘТЕ

Ел саен Җир йөзендә яшәүче һәр 250 кешенең берсе тромбтан вафат була. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасыннан алынган рәсми саннар шундый. Организмны зарарлау гына түгел, кеше гомерен мизгел эчендә өзүе белән дә мәкерле бу чир. Аннан ничек сакланырга? Тромб ни өчен өзелә?

Терапевт-кардиолог, медицина фәннәре кандидаты, доцент Ленар КАШАПОВ сорауларга ачыклык кертте.

:: Тромб барыннан да бигрәк нәрсәсе белән куркыныч?
– Тромб – гади генә әйткәндә, оешкан кан. Ул кан тамырларын томалый. Тромбның билгеләре аның кайсы органгадагы кан тамырында (баш мие, йөрәк, аяк һ.б. кан тамырында) хасил булуына бәйле. Мәсәлән, тромб аяк кан тамырларында хасил булса, аяк сызлый, авырая, кызара. Йөрәк кан тамырларында булса, ул инфарктка ук китерергә мөмкин. Андый чакта йөрәк турысында көчле авырту сизелә, кеше аңын җуярга мөмкин. Баш миендәге тромб исә еш кына инсультка китерә. Үпкәләрдә тромб барлыкка килгән очракта кешенең тыны кысыла. Сүз уңаеннан, тромб – йөклелек чорында да еш күзәтелә торган күренеш.

:: Коронавирус котырган чорда тромб турында аеруча еш ишетергә туры килде...
– Коронавирус, дөрестән дә, тромб килеп чыгу ихтималын арттыра. Бу инде фәнни яктан расланган. Коронавирус вакытында кан куера. Бу бигрәк тә вак кан тамырлары өчен куркыныч. Ковидтан соң тромб барлыкка килүне кисәтү өчен, кан сыеклагыч дарулар эчәргә киңәш ителә. Әмма аларны табиб белән киңәшкәч кенә кулланырга ярый. Аларны үзлегеңнән генә файдалану куркыныч – кан китәргә мөмкин.

:: Тромб ни сәбәпле пәйда була?
– Аякларда, нигездә, аз хәрәкәтләнү аркасында пәйда була. Операция кебек җитди процедурадан аяклар озак вакыт хәрәкәтләнмичә торса да, мондый куркыныч арта. Тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану да тромб хасил булуга китерә ала. Нәселдәнлек, контрацептик чаралар да – тромбка китергән сәбәпләр рәтендә. Йөрәк кан тамырындагы тромб та нигездә алда телгә алынган сәбәпләр аркасында килеп чыга. Моннан тыш шикәр чире, симерү, югары кан басымыннан (артериаль гипертензия) интеккән кешеләргә дә яный бу куркыныч.

:: Тромб варикоз аркасында пәйда була аламы?
– Әйе, вакытында дәваламасаң, варикоз да тромбка әверелергә мөмкин. Билгеле булганча, варикоз кан тамырлары киңәю, ялкынсынудан гыйбарәт. Тиз арада чарасын күрмәсәң, тромб барлыкка килүен көт тә тор.

:: Тромб ни өчен өзелә?
– Кагыйдә буларак, гадәттә, аякларда пәйда булган тромб өзелә. Әгәр тромб кечкенә булса, ул кан тамырының бер өлешен генә зарарлый да, кеше аны сизмичә дә калырга мөмкин. Кан тамырын зур тромб томаласа, кешенең гомере дә өзелергә мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

vk.com

Профилактика өчен

✓ Тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләрдән баш тартыгыз.
✓ Операциядән соң аяк озак хәрәкәтләнмичә торса, канны сыеклата торган дарулар эчәргә кирәк. Бу шулай ук тромб булмасын өчен кирәк.
✓ Кан тамырлары киңәйгән (варикоз) кешеләргә игътибарлы булырга кирәк. Ул шулай ук тромб хасил булу ихтималын арттыра.
✓ Кан авырулары булган, каны куерудан интеккән кешегә вакытында чарасын күреп, дәваланып торырга кирәк.
✓ Тромбны кисәтү өчен, һәрчак хәрәкәттә булу зарур. Болай эшләгәндә кан әйләнеше яхшыра, кан тамырлары тыгылу ихтималы кими.
✓ Канны, андагы холестерин күләмен даими тикшертеп торырга кирәк. Холестеринны киметмәсәң, тора-бара ул кан тамырларында тромб кебек оешачак.
✓ Чиста су эчү файдалы.
✓ Гормональ дарулар эчкәндә, контрацептик чаралар кулланганда сак булырга кирәк.
✓ Гәүдә авырлыгын һәрчак контрольдә тотыгыз.

Ишеттегезме?

Киемеңә карап – саулыгы

Сәламәтлек кием аркасында да бозылырга мөмкин! Стилист Анастасия Дзыба «Подмосковье сегодня» басмасына биргән әңгәмәсендә шулай дип белдергән. «Бүген кибетләрдә флис катламлы, экокүннән тегелгән чалбарлар еш очрый. Алар тыштан матур булса да, сәламәтлек өчен зыянлы. Алар тәнне сулатмый, кеше тиз тирли. Шуңа күрә эчке катламы юка булган экокүннән тегелгән чалбарга өстенлек бирергә кирәк. Кызганыч, алар кибеттә сирәк очрый», – ди стилист.

Белгеч үз үлчәмеңдәге яки бер үлчәмгә зуррак булган аяк киеменә өстенлек бирергә киңәш итә. Кыскан аяк киемен, зураер әле, дип алырга кирәкми, кыскасы. Кыскан аяк киеме бармакларга басып тора. «Нәтиҗәдә алар формасын үзгәртергә мөмкин», – ди белгеч.

Саклап куй!

САЛКЫН ТИГӘННӘН

100 мл кайнар суга 1 чәй кашыгы вакланган анар (гранат) кабыгы салып, 20 минут төнәтегез. Шуны көнгә 3 тапкыр 2шәр чәй кашыгы эчәсе. Дәвалану курсы – бер атна. Төнәтмә иммунитетны күтәрә.

ЮТӘЛДӘН

1 литр суга 500 г әрчеп туралган суган, 50 г бал, 40 г шикәр комын салып болгатып, сүрән утта 3 сәгать төнәтергә кирәк. Шуны көнгә 3 тапкыр берәр аш кашыгы кабарга киңәш ителә.

Табигать шифаханәсе

Лимонны дус итәр чак

Лимонның шифасы әйтеп бетергесез. Ул тукымаларны тукландыра торган С витаминына, А, B_1, B_2, Д, Р витаминнарына бай. Лимон косметологиядә дә даими кулланыла.

Тамак шешкәндә телемләп киселгән лимонны авызга кабып суырып йотарга кирәк. Моны сәгать саен кабатларга. Бигрәк тә лимонның кабыгы файдалы. Аны чәйнәгәннән соң, С витамины тамак төбендәге бактерияләрне үтерсен өчен, башка ризык капмый торырга кирәк.

Томау төшкәндә борынга көнгә 5–6 тапкыр берничә тамчы лимон суы тамызырга.

Вирусларга каршы чөгендер һәм лимон суы кушылмасы – иң яхшы чара.

Баш авыртканда лимон кабыгының ак элпәсен әрчисең һәм юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотасың. Күп тә үтми, лимон кызарып чыгар, ә баш авыртуы бетәр.

Күңел болганганда лимонның кабыгы белән йомшагы арасындагы ак элпә ярдәмгә килә. Косасы килгәндә, берәз гына баллы лимонлы су эчәсең һәм сохари ашыйсың.

Йөткергәннән: тигез күләмдә бал, лимон суы, шикәр комы алып кайнатасың да, өянәк башлангач, 1 аш кашыгы күләмендә кабып куясың.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

СОҢГА КАЛСАҢ, ПОМИДОР ПЕШМИ

Озын еллардан соң бакчачылар киләсе сезон турында уйлый башлагандыр инде. Шулай да кышкы айларда аларга нишләргә соң?

«Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА киңәшләрен бирде.

Кыш – бакча сезонына әзерләнү өчен бик уңайлы вакыт. Иң элек язга мөһим эшләр исемлеген булдырып, орлык, туфрак, ашлама юнәтү мәсьәләсен кайгырта башлау, чәчү әйләнеше кагыйдәләрен үтәп, кая нәрсә утыртыласын уйлап кую кирәк. Бер семьялыкка керүче үсемлекләрне рәттән ике елдан да артыграк бер үк урында үстерү киңәш ителми (бәрәңгедән кала – ул урын алыштыруны әллә ни таләп итми).

Урын алыштырасы

Берочтан семьялыкларны да искә төшереп үтик. Кыяр, ташкабак, кабак, карбыз – кабак семьялыгына; татлы борыч, помидор, бәрәңге – бәрәңге семьялыгына; кишер, петрушка, укроп, кинза – зонтиклылар; гочица, редис, кәбестә, шалкан – кәбестә семьялыгына; суган, сарымсак – амариллис; борчак, ногыт борчагы – кузаклылар семьялыгына керә. Әйтик, бер елны татлы борыч үскән түтәлгә икенче елда курыкмыйча помидор утыртырга мөмкин әле. Ләкин инде өченче елда бу урында борыч яки томат начар уңыш бирәчәк. Түтәлләрне алыштырганда, теләсә кайсы культураны кузаклылар артыннан утырту бик яхшы. Бу җәһәттән кәбестә семьялыгы икенче урында тора. Мул уңышка өметләндергән үсемлекләрне утыртканда, менә шушы ике семьялыкны истә тоту әйбәт булачак.

Орлыклар һәм ашламаларны ышанычлы кибетләрдән генә сатып алыгыз. Базар тирәсеннән сатып алынганы сыйфатсыз булып чыгарга мөмкин. Ашлама, бигрәк тә пестицидларга игътибарлы булыгыз. Аларның сыйфатына бернинди шик калмаска тиеш. Сыйфатсыз ашлама үсентене юкка чыгару гына түгел, туфракны да озак елларга агулап куярга мөмкин.

vk.com

Аңлаешсызмы?

Помидорны үстермәгән кеше юк. Шуңа күрә аның орлыгына тәфсилләбрәк тукталып үтәргә кирәк. Орлык кабындагы аңлаешсыз язуларга карап аптырап калучылар да юк түгелдер. Әйтик, детерминант сортлы томат. Ачык туфракта тәбәнәк кенә булып, бик әйбәт үсә, «үги» ботаклар чыгармый. Әмма бер генә тапкыр уңыш бирә. Бер булса да, берәгәйле итеп: куагыннан 3–4 кило уңыш алырга мөмкин. Ә менә индетерминант сортлары теплица шартларын – җылыны һәм суны ярата. Мондый үсенте, «үги» ботаклар чыгарып, бик шәп үсә. Бөтен сезон буе уңыш бирә.

Тәмле булсын!

ЙОМЫРКА БЕЛӘН ИТ РУЛЕТЫ

Сәвия ГАЛИУЛЛИНА рецепты

Кирәк: *400 грамм фарш, 5 йомырка, 1 баш суган, 2 тырнак сарымсак, 2 помидор, 1 чәй кашыгы крахмал, яшел тәмләткеч, үсемлек мае, тоз, борыч, рәйхан, карри.*

Суган һәм сарымсакны ваклап турыйбыз да майлы табада, алтынсу төскә кергәнче, 3 минутлап кыздырып алабыз. Помидорларны ваклап турыйбыз.

Фаршка бер чи йомырка, помидор, сарымсак белән суган, тоз, борыч, рәйхан өстәп, әйбәтләп болгатабыз. Фольга өстенә 1 см калынлыкта җәябез. 3 йомырканы пешереп, фарш уртасына бөтен килеш бер рәткә тезеп куябыз. Өстенә крахмал сибәбез дә рулет итеп төрәбез.

Калган 1 йомырканы сытып, 1 чәй кашыгы карри өстибез һәм катнашманы рулет өстенә сылыйбыз. 180–200 градуска кадәр җылытылган мичтә 45 минут пешерәбез.

Әзер рулетны яшел тәмләткечләр белән бизибез. Матур да, тәмле дә ризык!

Исеңдә тот!

Аяк таймасын дисәң

Бозлавыкта таеп имгәнмәс өчен, аяк киеме табанын ничек шумый торганга әйләндерергә?

Наждак кәгазе. Аяк киеме табанын шуның белән ышкысаң, кытыршы хәлгә килеп, таймый башлаячак. Ләкин җиңелчә генә ышкыйсы, югыйсә табан материалына зыян килүе бар.

Тырнак игәве. Беренче карашка, сәеррәк корал, әмма файдасы бар. Бу очракта игәүнең тимердән ясалганы әйбәтрәк. Аяк киеме табанының бөтен өслеген, берникадәр көч куеп, шуның белән игәүләп чыгасы.

Чәч лагы. Аяк киеме таюдан котылуның тагын бер җиңел генә ысулы.

Составындагы химик эреткеч, табанны ябышучанга әйләндереп, тайдырмый. Моның өчен лакны, аяк киеме өстенә тидермичә генә, табанына яхшылап сиптерергә кирәк. Кимчелеге – вакытлыча гына кулланырга мөмкин. Юешрәк көндә тиз юылачак.

Тоз һәм резина җилеме. Шулар катнашмасын сылаганда, аяк киеме табаны шумый торганга, кытыршыга әйләнә. Моның өчен табакка бертигез күләмдә тоз һәм җилем салып, әйбәтләп болгатабыз. Кечкенә генә пумала ярдәмендә катнашманы табанга тигез итеп сылыйбыз. Кигәнче, кипкәнен бераз көтеп торырга кирәк.

Аяк киеме табанын «искертү». Моның өчен табанны чуерташ, гадәти таш белән ышкырга яки кытыршы өслектә: чуерташлы, тупас брусчаткалы юлда йөреп алырга мөмкин. Яңа аяк киеме өчен бигрәк тә әйбәт ысул.

Белеп тор!

Яңа яуган кардай

Саргаебрак киткән ак төстәге урын-җирне лимон согы белән агартырга мөмкин. Моның өчен, юганда, машинаның кер порошогы тартмачыгына ярты стакан лимон согы өстәргә кирәк. Болай эшләгәндә, җәймә, мендәр һәм юрган тышы яңа яуган кардай ап-ак булачак.

Май көйми

Атланмай белән кыздырганда, ризыгы да, мае да көебрәк, каралыбрак китә. Бу хәлдән котылу өчен, табаны иң элек үсемлек мае белән майлау әйбәт. Бу киңәшне истә тоткан очракта берни көймәячәк!

Алтынсу балык

Балык кисәкләрен, табага салганчы, кәгазь сөлге белән корытып, бераз тозларга кирәк. Болай эшләсәгез, балык таралып китмәячәк һәм ул алтынсу төскә кереп кызачак!

Хәйләсе бар

Сытканда, йомыркага төшеп калган кабыкны алу өчен кайвакыт шактый ук азапланырга туры килә. Хәйләсен белеп тору беркемгә дә зыян итмәстер. Бармак очын суда чылатсаң, кабык үзеннән-үзе диярлек бик җиңел ияреп чыгачак.

МӘҢГЕЛЕККӘ ӘЗЕРЛЕК

Адәм баласының бу дөньядагы сәгате санаулы. Кемнең кайчан Аллаһы Тәгалә каршына басачагы билгеле түгел. Үлем һәркайсыбызның ишеген шакыр. Динебез аннан курыкмаска һәм әзерлекне хәзердән үк башларга кирәк дип өйрәтә.Зиратта алдан җир алып кую – дөрес гамәлме? Мәет озатуларын күреп калсаң, ни әйтергә? Бер кабергә берничә кешене күмү рөхсәт ителәме?

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН җавап бирде.

:: Зиратта алдан җир алып куйсаң, үлемеңне якынайтасың, диләр. Дин буенча ничек?

– Үлемне якынайта, ерагайта дию дөрес булмас. Күпме гомер яшисен Аллаһы Тәгалә тәкъдиребезгә язып куйган. Шуннан кубрәген дә, азрагын да яшәмәбез. Без кайда һәм кайчан үләсебезне алдан белмибез. Зиратта җир алып кую рөхсәт ителә. Кайсы мәхәлләдә вафат булабыз, шунда җирләү хәерлерәк.

:: Хәрбиләрне оркестр уйнатып, ядрә шартлатып, автоматтан атып озату күренешләре бар. Әйтик, хәрби – мөселман кеше, ди. Аны болай күмү дөресме?

– Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.): «Зиратка кергәндә аяк киемнәрен дә салыгыз, әрвахларга тавыш килмәсен өчен», – дигән бер хәдистә. Гомумән, зиратта тавыш булмаска тиеш. Машинада йөргәндә дә, юлыбыз зират аша узса, тизлекне киметеп, эчтән дога кылып узарга кирәк.

Хәрбиләрне хөрмәт итәбез. Әмма мондый күмүләр – динсезлек вакытыннан калган күренешләр. Хәрбиләребезгә дә дога кирәк.

:: Мәрхүмгә доганы кемнән укыттыру дөресрәк?

– Рәсүлебез исән чакта, доганы пәйгамбәребездән (с.г.в.) укытканнар. Ул дөньядан киткәч, иң якын шәкертләреннән. Ягъни изге кешеләрдән. Хәзерге дәвердә имамнардан укытырга тырышалар. Хаҗлы, намазлы, уразалы кешеләрдән дога укытсак, хәерле булыр. Ләкин рәсүлебез, балалар-оныклар, туганнар да мәрхүм өчен дога кылсын, дип кисәтә.

:: Авариялардә үлүчеләргә истәлек итеп, һәлакәт булган урыннарда еш кына таш куялар. Бу дин ягыннан рөхсәт ителәме?

– Һәрберебез шулай таш куя башласак, юл буйлары тулы таш булыр. Елына күпме кеше үлеп тора бит. Аллаһы Тәгалә сакласын! Вафат булган кешегә таш кирәкми. Аңа дога кирәк. Ташка сарыф итәсе акчасын ятимгә, мескенгә сәдака итеп бирсә, бәлки, күпкә хәерлерәктер дә.

:: Бер кабергә берничә кешене күмәргә ярыймы?

– Бер ләхеткә, бер кабергә бер кеше ята. Әмма, әйтик, бер үк көнне ир дә, хатын да вафат булды, ди. Андый вакытта нишләргә? Ике ләхет алып, бер кабергә салалар. Әмма һәр мәеткә аерым кабер булса, хәерлерәк.

:: Йөкле хатын-кызга мәеткә карарга ярамый, диләр. Моны ничек аңларга? Диндә чикләү бармы?

– Хатын-кыз – йомшак күңелле зат. Аны Аллаһы Тәгалә шундый итеп яраткан. Бала көткәндә, гүзәл затның

dumrt.ru

күңеле тагын да йомшара, тагын да нечкәрә. Мәетне озатканда, хатын-кызга аның белән саубуллашырга, әлбәттә, мөмкин. Әмма ул бик тә хисләнә, елый икән, бу эштән ераграк тору хәерлерәк булыр. Чөнки моның балага зыяны булырга мөмкин. Ярамый дигән сүзләр дә шуңа бәйле. Йөкле килеш зиратка бармаска дигәне дә хатын-кызның бар нәрсәне күңеленә якын алуы сәбәпле әйтелгән.

:: Кабер өстенә ясалма чәчәкләр куярга ярамый, дип беләбез. Ә чын чәчәкләр үстерергә, агач утыртырга ярыймы?

– Мондый сорауларга төгәл җавап бирү авыр. Нәрсәсе белән? Чөнки һәр мәхәлләнең зиратында үз кагыйдәсе бар. Нинди гадәтләр кергән, мәсьәләне шуның буенча хәл итәргә кирәк. Сезнең авылда зиратта каберлекләргә чәчәкләр утыртырга рөхсәт ителә икән, утыртыгыз.

:: Мәет озатуларын күреп калсаң, ни дияргә яисә нинди дога укырга?

– Әйе, мәет турында ишетсәк тә, күрсәк тә, дога кылабыз. «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун – Һәр кешенең гомере Аллаһыдан һәм Аллаһының Үзенә кайтачакбыз», – дибез.

:: «Бу кешене үле килеш истә калдырырга теләмим», – дип, мәет озатырга килмәгән, кайтмаган кешеләр дөрес эшлиме? Яисә мәет озатуда катнашу мәҗбүриме?

– Кайгы турында ишетсәң, чакырганны көтмә, бар. Җеназада катнашу – саваплы гамәл. Мондый кешегә пәйгамбәребез (с.г.в.) Ухыт тавы кадәр савап булыр, дигән. Хаҗ кылган кешеләр бу тауның нинди зур булуын белә. «Үле килеш истә калдырмыйм әле», – дисәң, йөзен ачып карама. Мәет кәфенлектә була бит. Кәфенлек аша йөзе күренми. Әмма җеназада катнашып, туганнарына ярдәм итсәк, моннан да хәерлесе булмас.

:: Мәетне җирләгәч, аны ярып карау өчен казып алырга рөхсәт ителәме?

– Диндә мәетне яру, мәеткә зыян китерү рөхсәт ителми.

Бу кызык!

Җәннәт әһелләре нинди була?

Гыйкримә (сәхабә исеме) болай дип әйткән:

«Җәннәт әһеленең ирләре дә, хатыннары да утыз өч яшьлек кебек, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнең буе кебек – алтмыш аршын, сакалсыз, мыексыз егетләрдер, күзләре сөрмәле. Алар өчен җитмеш кием булыр, һәрбер киемнең төсе һәр сәгатьтә җитмеш төскә үзгәрер. Ирләр йөзләрен хатыны йөзендә, күкрәгендә һәм хатынның балтырында күрерләр. Хатын йөзен иренең йөзендә, күкрәгендә һәм балтырында күрер. Җәннәттә алар төкермәсләр, сеңгермәсләр һәм ул җәннәт кешесе рәнҗүдән, моннан өстен булганнардан ерактыр».

Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип әйткән:

*«Өммәтемнең җәннәткә керүчеләренең беренче төркеме ундүртенче кичтәге ай төсендә булыр, ә алардан соң ук керүчеләрнең төсе иң якты йолдыз кебек булыр. Моннан соң аларга урыннар бирелер. Анда алар бәвелләнмәсләр, бәдрәфкә бармаслар, ягъни йомышларын үтәмәсләр, төкермәсләр һәм какырмаслар. Аларның тараклары алтындыр, аларның хуш ис чыгару өчен булган күмер савытлары үлүвәтдер (пыскып янганда хуш ис чыгара торган агач төре), ягъни гуд агачыдыр. Аларның тирләре яфәрдер һәм аларның яратылышлары (натура мәгънәсендә. – **Ред.**) бер иренең яратылышы кебектер, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнеке кебек, алтмыш аршын булыр».*

(«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан)

Гыйбрәт ал!

Изгелек һәм игелек көне

Көннәрнең берендә пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең шәкертләре янына чыккан да аларны чын күңелдән бәйрәм белән тәбрик иткән. Шәкертләр бу хәлгә аптырап калган. Бер-берсенә карашканнар да: «Нинди бәйрәм икән соң бүген?» – дип уйлашканнар. Бераздан бүген Гашурә көне икәнен исләренә төшергәннәр һәм бер-берсен бу бәйрәм белән котлаганнар.

Икенче көн җитә. Бу җомга көн була. Пәйгамбәребез (с.г.в.) янә шәкертләре янына чыгып, аларны бәйрәм белән тәбрикләгән. Җомга көн мөселман кеше өчен зур бәйрәм икәнен беләбез бит, монысына берәү дә аптырамаган.

Өченче көнне тагын шәкертләр янына чыгып, пәйгамбәребез (с.г.в.) бәйрәм белән котлаган. Инде шәкертләр тагын аптыраган. Пәйгамбәр (с.г.в.) исә аларга карап:



– Бүген изгелек һәм игелеккә мул көн. Мөселман кеше, Аллаһы Тәгаләгә ышанган кеше өчен һәр көн – зур бәйрәм, чөнки ул изгелек һәм игелек кылу аркасында Аллаһыга якыная һәм аның газабыннан ерагая, – дип аңлаткан.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

СИН МАТУР, СИН ЧИБӘР...

Тышкы матурлыкка күз кызыга. Бүген ул кайбер өлкәләрдә бөтенләй дә беренче планга чыкты. Илдә яшәүчеләрнең 69 проценты карьера төзегәндә нәкъ менә тышкы матурлыкның мөһим булуын әйткән. Сәхифәбез кунаклары бу хакта ни уйлый икән? Матурлыкны яраткан сәхнәдә матурлык кына җитәме?

«Безнең тамашачы матурлык ярата»

Юмор остасы, алып баручы **Әбри ХӘБРИЕВ,** матурлыктан бигрәк, хезмәт һәм осталык теләсә нинди өешманың эш нәтиҗәсен югары дәрәҗәгә күтәрергә сәләтле дип саный. Бүгенге тамашачының да тышкы матурлыкка күбрәк игътибар итүенә борчыла. «Безнең тамашачы матурлык ярата. Тавышы нинди генә көчле булмасын, җырчының киеме бераз «зәгыйфьрәк» икән, ул аңа, ни кызганыч, әллә ни игътибар итми. Мин күп кенә матур тавыш ияләре булган, әмма шуның аркасында бик күтәрелә алмаган егет-кызларны беләм. Шәп киемнәр тектерер өчен шәп кенә акчалар кирәк бит. Ә ул акчаны башта эшләп табарга кирәк. Тагын шул тавыш белән генә күтәрелә алмауга барып тоташабыз...» – ди ул.

«Карьера төзегәндә шуннан башка булмый»

Җырчы **Алсу ӘБЕЛХАНОВА** исә хәзерге көндә тышкы кыяфәт сәхнә кешесе өчен генә түгел, шактый һөнәр ияләре өчен мөһим дип саный. «Әйтик, бүгенге сәясәтчеләрне генә алыйк. Алар – һәрдаим халык күз алдында, һәрвакыт игътибар үзәгендә. Алар өчен тышкы кыяфәт бик мөһим. Гомумән, бүген карьера төзегәндә шуннан башка булмый. Ә элек алай түгел иде», – ди ул. Сәхнәгә әйләнеп кайтсак, кайчак тышкы матурлык эчтәлеккә караганда да мөһимрәк була башлады, дип саный җырчы. «Билгеле, сәхнәнең тавыш, җыр сайлау, хит ясау кебек мөһим яклары бар. Әмма без беренче планга визуал чыккан чорда яшибез», – ди Алсу Әбелханова.

«Сәхнә матурлыкны ярата»

Шоумен **Айрат ИЛЬЯСОВ** әнә шулай ди. «Артист кеше матур булырга тиеш» дигән сүзне ишеткән бар. Сүз дә юк, ничек кенә булса да, сәхнә матурлыкны ярата. Ләкин җырчының тавышы да булса, тагын да яхшырак булыр иде», – диде ул. Анынча, матурлыкның тагын нинди уңай яклары бар икән соң? «Кайчак матур кешегә кайбер ялгышлар гафу ителә», – диде ул, уены-чыны белән.

«Өч көнлек кенә ул...»

Камал театры артисты **Фәннүр МӨХӘММӘТҖАНОВ** тышкы матурлык турында әнә шулай ди. «Тышкы матурлык – акча корты, эчке матурлык – оҗмах йорты. Билгеле, безнең җәмгыятьтә тышкы матурлык бик зур роль уйный. Ләкин күңелең матур булмаса, тышкы матурлык өч көнлек кенә ул!» – ди актер. Театр өлкәсендә чибәрлек белән генә алдырып булмый. «Бездә матурлык башкача чагыла. Актер мөлаем, сөйкемле, тамашачы өчен кызыклы булырга тиеш. Күңеле бай, матур кешеләр генә шундый була. Ә кыяфәт... Хәзер бит грим әллә нинди ямьсез кешене дә матур итә. Тышкы матурлык экран өчендер ул. Анда инде эчке дөньяң эчтә кала...»

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге яңа сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бу юлы без Татарстанның халык артисты, Тинчурин театры актрисасы Зөлфия ВӘЛИЕВА белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Балам.

:: Егылганда тартып торгызган сүз?
– Мин көчле.

:: Бик каты ярлаган, рәнҗеткән сүз?
– Син булдыксыз.

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– Мин хаклы түгел.

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Син миңа кирәк. Яратам.

Аннан-моннан

Узып баручы атна ниләр белән истә калды? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Зәйнәб Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов – яңа статуста! 14 гыйнварда аларның уллары, җырчы Акбулат сөйгәне Әдилә белән кавышты – яшьләрнең никахлары узды.

Айгөл белән Алсу гомрә хаҗына киткән. Җырчылар Айгөл Бариева белән Алсу Фазлыева турында сүзебез. Икесе дә елларын изге сәфәрдән башларга булган алар. Социаль челтәрдәге битләрендә шулай дип язганнар. Ә без исә исән-сау әйләнеп кайтуларын телик!

Яңа атказанганнар. Күптән түгел баянчы Булат Шәрипов, җырчылар Энҗе Шәймурзина, Анастасия Макарова, композитор Риваль Хисмәтуллинга «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелде. Медаль алучылар моның белән генә бетмәде. Парлы җырчылар Эльмира Гыйльфанова белән Рафил Җәләлиев «Мәдәнияттәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләнгән. «Югалып та калдык. Алга таба да матур итеп халыкка хезмәт итәргә язсын!» – дип яза Эльмира.

Таиландта – татар концерты. Җырчы Элвин Грей, Таиландка кадәр барып, концерт куйган. Килгән тамашачыларның беришe – татар блогерлары. Татар һәм башкорт эстрадасы белән араларны өзгәч, концертларны шулай читкә барып куясыдыр инде ул... «Барысын ташлыйм да Мәскәүгә китәм – анда мине көтәләр», – дисә дә, татарча җырлары чыгып тора тагын.

24 гыйнвар | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.15 «Таяну ноктасы» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Автомобилист» – «Ак Барс» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сәйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «БОЛЬШОЙ ДОМ» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лига в лицах» 12+
06.30 Битва роботов 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.50, 03.55 Новости
07.05, 15.30, 18.55, 21.45, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Профессиональный бокс. К. Цзю – Б. Таки 16+
13.00 «Есть тема!»
15.00, 01.00 «Вид сверху» 12+
16.55 Футбол. Товарищеский матч. «Зенит» (Россия) – «Чонбук» (Корея)
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Динамо» (Минск)
21.55 Футбол. Кубок Испании. 1/4 финала
01.30 Матч! Парад 16+
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Мешков Брест» – «Пермские медведи» 6+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА – УНИКС 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
00.50 «СОЛО ДЛЯ ПИСТОЛЕТА С ОРКЕСТРОМ» 16+
03.05 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.15 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.25 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ВРЕМЯ ЖЕНИТЬСЯ» 16+
19.00 «СЛОВНО НЕ БЫЛО РАЗЛУКИ» 16+
02.50 «СКОЛЬКО ЖИВЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
06.00 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ОСТРОВ СОКРОВИЩ» 12+
12.20, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 03.55 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «НОЧНОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ» 12+
00.55 «ПЕРЕД РАССВЕТОМ» 16+
02.20 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа» 12+
03.15 «Зафронтовые разведчики» 16+

25 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Классный час» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Башваткыч» 12+
17.30 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 16+
00.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Азбука долголетия» 16+
01.40 «Кто мы татары?» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.00 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10. 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сәйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.25 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 12+
21.00 «Время»
22.00 «БОЛЬШОЙ ДОМ» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.35, 03.55 Новости
07.05, 15.30, 18.55, 21.25, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Профессиональный бокс. С. Ибрагимов – Р. Остин 16+
13.00 «Есть тема!»
15.00, 01.00 «Большой хоккей» 12+
16.30 Смешанные единоборства. UFC. М. Анкалаев – Дж. Уокер 16+
17.40 «Короли. Плоть и кровь» 12+
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» – «Руна»
21.55 Футбол. Кубок Испании. 1/4 финала
01.30 Матч! Парад 16+
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «СКА-Минск» – «Чеховские медведи» 6+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Пари Нижний Новгород» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
00.50 «Поздняков» 16+
01.05 «СОЛО ДЛЯ ПИСТОЛЕТА С ОРКЕСТРОМ» 16+
03.20 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.15 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.25 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «СТО ДОРОГ» 16+
19.00 «ВСЁ РАВНО ТЫ МОЯ» 16+
02.50 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
06.00 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.45 «ВЕРТИКАЛЬ» 12+
12.35, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 04.45 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО «СМЕРТЬ» 12+
02.00 «НОЧНОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ» 12+
03.30 «Часовые памяти» 16+
04.20 «Москва фронту» 16+

26 гыйнвар | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести ПФО»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 01.20 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Ак барс» 6+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «Сәйләшергә вакыт» 16+
23.10 «КВН РТ-2024» 16+
23.40 «СРЕДНИЙ РОД. ЕДИНСТВЕННОЕ ЧИСЛО» 16+
01.45 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
02.00 «Точка опоры» 16+
02.50 «ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ» 16+
04.25 «Җырлыйк әле!» 12+
05.15 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
18.20, 04.20, 23.10 «Ком сәгате» 16+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Ватандашлар» 16+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
03.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «ОДЕССА» 16+
23.55 «ДОРОГИЕ ТОВАРИЩИ!» 16+
01.55 Церемония вручения премии «Золотой Орёл»

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 03.55 Новости
07.05, 15.00, 00.00 Все на Матч!
10.05, 03.35 «Небесная грация» 0+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Футбол. Еврокубки 6+
12.35 «Лица страны» 12+
13.00 «Есть тема!»
15.30, 21.45 Смешанные единоборства
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА – ЦСКА
01.00 Битва роботов 12+
01.30 Матч! Парад 6+
02.00 Гандбол. Кубок России. 1/4 финала. Женщины. «Ростов-Дон» – «Звезда» 6+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» – «Руна» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ШЕФ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.50 «Квартирный вопрос» 0+
02.40 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.15 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 02.50 «Понять. Простить» 16+
12.00 «Порча» 16+
13.05, 03.50 «Знахарка» 16+
13.40, 04.15 «Верну любимого» 16+
14.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.50 «ОДИНОЧКИ» 16+
19.00 «ПО ТОНКОМУ ЛЬДУ» 16+
23.20 «ОДНО ТЁПЛОЕ СЛОВО» 16+
04.40 «Предсказания: 2024» 16+
05.20 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+

ЗВЕЗДА
08.10, 09.20 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
10.25, 13.25 «БАЛТИЙСКОЕ НЕБО» 12+
14.40, 15.05, 17.15 «ЛЕГЕНДА ДЛЯ ОПЕРШИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.50 «ПОРОХ» 12+
02.20 «ПРИЗНАТЬ ВИНОВНЫМ» 12+
03.45 «Освенцим» 16+
05.05 «Зафронтовые разведчики» 16+

27 гыйнвар | Шимбә

ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00, 01.35 Мирсәет Сөнгатуллинның 70 яшьлек юбилей кичәсе 12+
16.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
16.30 «Әдәби хәзинә» 16+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «МЕЖДУ НАМИ, ДЕВОЧКАМИ» 16+
23.40 «КАКАЯ У ВАС УЛЫБКА» 6+
01.10 «Музыкальный майдан» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Өмет йолдызы» 16+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Рәхмәт сиңа» 16+
22.15 Т.Миңнуллин. «Әниләр һәм бәбиләр». Уфа «Нур» татар дәүләт театры спектакле 16+
00.35 Т.Миңнуллин. «Шулай булды шул». Салават башкорт дәүләт драма театры спектакле 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ
06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости
10.15 К 80-летию со дня полного освобождения Ленинграда от фашистской блокады 12+
11.05 «БЛОКАДА» 16+
12.00 Новости
18.00 Вечерние новости
18.20 «Своя колея» 16+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.25 «Блокадное рондо» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00. 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Доктор Мясников» 12+
12.35 «Иван Зубков. Спаситель Ленинграда» 12+
13.20 «СЕДЬМАЯ СИМФОНИЯ» 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 Концерт-реквием к 80-летию полного освобождения Ленинграда от блокады
22.30 «КРИК ТИШИНЫ» 6+
00.05 «СВЕТЛАНА» 12+
03.35 «САМАЯ ЛЮБИМАЯ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. Karate Combat 16+
07.00, 10.00, 15.45, 19.00, 03.55 Новости
07.05, 13.25, 15.50, 19.05, 22.00, 01.00 Все на Матч!
10.05 «Команда МАТЧ» 0+
10.25 «София и Софья – две медали» 12+
11.40 Лыжные гонки. Матч ТВ. Гонка звёзд
13.55 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. КПРФ – «Синара»
16.55 Футбол. «Зенит» – «Урал»
19.55 Футбол. Чемпионат Италии
22.40 Футбол. Кубок португальской лиги. Финал 4-х
02.00 Футбол. Чемпионат Германии 6+
04.00 «Вы это видели» 12+
05.00 Бокс. Bare Knuckle FC

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.20 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.10 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса» 16+
02.15 «Дачный ответ» 0+
03.05 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
08.45 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.50 «ПЛОХАЯ ДОЧЬ» 16+
02.20 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
03.10 «6 кадров» 16+
03.40 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+

ЗВЕЗДА
05.40 «ЗОЛОТОЙ ГУСЬ» 6+
06.50 «Я – ХОРТИЦА» 12+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «Хроника Победы» 16+
09.50 «ГОЛУБАЯ СТРЕЛА» 12+
11.40 «Мужики» 16+
12.10 «СССР. Знак качества» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров» 16+
14.30 «Легенды науки» 12+
15.20 «Главный день» 16+
16.10 «Время героев» 16+
16.35 «Легенды разведки» 16+
17.10 «РАЗМАХ КРЫЛЬЕВ» 12+
19.25 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
21.15 «Галерея звезд» 12+
22.55 «БАЛТИЙСКОЕ НЕБО» 12+
01.55 «ЛЕГЕНДА ДЛЯ ОПЕРШИ» 16+
05.00 «Часовые памяти» 16+

28 гыйнвар | Якшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 Марат Мухин хитларыннан концерт 16+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Барыс» – «Ак барс» 6+
16.30 «Видеоспорт» 16+
17.00 «Ком сәгате» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
22.00 «Семь дней» 16+
23.00 «ГОНКА С ПРЕСЛЕДОВАНИЯМИ» 12+
00.35 «НА ЧУЖОМ ПРАЗДНИКЕ» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 16+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Нечкәбил-2023» 12+
15.40 «Олы юл әйтте…» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җыры кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 М.Гыйләҗев. «Бала баласы балдан татлы». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
06.00 Новости
06.10, 00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.00 Новости
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.00 «ИЩИТЕ ЖЕНЩИНУ» 12+
16.55 К 70-летию Леонида Ярмольника 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «КОНТЕЙНЕР» 16+

РОССИЯ 1
06.10 «СИНДРОМ НЕДОСКАЗАННОСТИ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.35 «Большие перемены»
12.35 «Блокада. День 901-й» 16+
13.20 «СЕДЬМАЯ СИМФОНИЯ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Ленинградская симфония на берегу Невы

МАТЧ ТВ
06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Д. Санчес – Н. Каттер
09.00, 10.00, 13.00, 03.55 Новости
09.05, 13.05, 22.00, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Команда МАТЧ» 0+
10.25 «Король ринга. Николай Королёв» 12+
11.40 Биатлон. Матч ТВ. Гонка звёзд
13.55 Футбол. Товарищеский матч. «Зенит» (Россия) – «Аль-Фатех» (Саудовская Аравия)
15.55 Баскетбол. Фонбет Кубок России. Женщины. Финал 4-х
17.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» – «Зенит-Казань»
19.55 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 «Что за спорт?» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС – «Автодор» 6+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» – «Динамо-Метар» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «ХАМЕЛЕОН» 16+
00.25 «Звезды сошлись» 16+
02.00 «Основано на реальных событиях» 16+
03.25 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.45 «ПЛОХАЯ ДОЧЬ» 16+
10.40, 02.10 «СЕЗОН ДОЖДЕЙ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.45 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
05.20 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
06.00 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО «СМЕРТЬ» 12+
07.20 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
13.50, 03.30 «Забытые войны России» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «ГОЛУБАЯ СТРЕЛА» 12+
01.25 «Я – ХОРТИЦА» 12+
02.35 «Гомбожаб Цыбиков. Паломник особого назначения» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Хәйруллина** Дилбәр Талип кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасының радио-телевидение тапшыру үзәге» филиалы производство лабораториясе инженеры **Гаффаров** Фәрит Гыйльман улына, «Россия почтасы» акционер җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Операцион идарә департаменты производство процесслары бүлеге җитәкчесе **Козловская** Алевтина Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Белдерү

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии с Постановлением Правительства № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан https://mpt.tatarstan.ru/informatsiya-o-proektah-investitsionnih-programm-3469637.htm и АО «Татэнергосбыт» https://tatenergosbyt.ru/about/open-info/market-subject/investment-info/?year=2024 размещена в полном объеме информация об итоговом проекте корректировки инвестиционной программы АО «Татэнергосбыт» на 2023–2025 гг. и об итоговом проекте инвестиционной программы АО «Татэнергосбыт» на 2024–2026 гг.

ЮРИСТ СЕЗНЕ ТЫҢЛЫЙ

Ничек? Нишләргә? Кая барырга? Газетабыз битләрендә «Юрист сезне тыңлый» дигән сәхифәне укучыларыбызның әнә шул сорауларына җавап табарга ярдәм итү өчен булдырдык. Бу атнада «ВКонтакте» сәхифәсендә һәм «WhatsApp» номерына кабул ителгән сорауларга җавапны юристыбыз Булат ЗАКИРОВ белән бергәләп әзлӓдек.

? Минем әниемә – 90 яшь, урын өстендә ята. Күп кенә хроник авырулары бар, күптән урын өстендә инде ул. Әнинең: «Балалар, үлгәч, мине моргка ярдырырга алып бармагыз», – дигән сүзе бар. Әле хәзер дә шул сүзне әйтә. Хәзер шулай икән: 70, 80, 90, 100 яшьтәме, барыбер ярдырырга кушалар, ди. Авыруны һәрдаим күрсәтеп торсаң да файда юк, барыбер моргка алып китәләр икән. Мин әни үлгән очракта аны ярдырудан баш тарта аламмы?

Исемем редакция өчен генә

Җавап:
– Кешенең үлеме сәбәпләре һәм авыру диагнозы турында мәгълүмат алу максатыннан, закон нигезендә патологик-анатомик аутопсия үткәрелә.

Аутопсиядән дини сәбәпләр буенча баш тартырга мөмкин. Моның өчен үлгән кешенең якын туганына яки законлы вәкиленә танатология бүлеге мөдире исеменә язма рәвештә гариза бирергә кирәк. Гаризада төп мәгълүматлардан тыш, аутопсиядән баш тарту сәбәбе дә күрсәтелә. Аутопсияне үткәрергәме-юкмы икәнен патологоанатом хәл итә.

Патологик-анатомик аутопсия үткәрүдән түбәндәге очракларда баш тарту мөмкин түгел: көч куллану нәтиҗәсендә үлгән дип шикләнү; үлемгә китергән авыруның соңгы клиник диагнозы яисә төп сәбәбе билгеле түгел; үлүче стационар шартларда иң кимендә бер тәүлек дәваланган; даруларны артыгын куллану яисә дару туры килмәгән очрак; наркоз, операция, кан салдыру кебек медицина хезмәтләре аркасында үлем; инфекция, онкология сәбәпле үлем; экологик катастрофага бәйле үлем; йөклелек, бала табу, үлгән бала табу; судмедэкспертиза таләп ителү.

Бу очракларда хәтта язма гариза булганда да, аутопсия үткәрүдән баш тарту мөмкин түгел!

? Өч бала белән административ отпускта мин. 3 яшькә кадәр болай утырдым инде, тагын ничә яшькә кадәр үз хисабыма шулай утыра алам икән? Эш урынымнан эшкә чыгарга кыстыйлар... Бүтән ял биреп булмый инде, диләр. Закон буенча ничек икән?

Гөлназ

Җавап:
– Балага өч яшь тулганчы, бала карау буенча отпуск хезмәткәргә гариза буенча бирелә. Хезмәт хакы сакланмаган ялның («административ») дәвамлылыгы хезмәткәр белән эш бирүче арасындагы килешү буенча билгеләнә. Ягъни дәүләт, балага өч яшь тулганчы, бала карау өчен отпуск гарантияли. Декретны балага 6 яшь тулганчыга кадәр озынайту нормалары каралмаган. «Административ» отпуск бирү эш бирүченең ихтыярында кала.

? Шәһәр читендә торабыз. Күршем тәрәзә каршына 2,1 метр биеклектәге иске шифердан койма куйды да, безнең өй эче караңгыланды. Дөрес эшләдеме икән ул? Закон буенча нинди биеклектә, нинди материалдан куярга тиеш иде ул аны?

Надия

Җавап:
– Участоктагы койма параметрлары участок урнашкан конкрет торак пунктның муниципаль берәмлек администрациясе тарафыннан билгеләнә. Ягъни койма биеклеге муниципаль законнар белән көйләнә. Мәсәлән, Казан шәһәренең Шәһәр төзелеше уставында күрсәтелгән нормативларда койманың максималь биеклеге: а) урамнар һәм юллар буйлап – 2,5 м; б) торак йортның алгы ягындагы күрше участоклар арасында – 2,5 м; в) торак йортның арткы ягындагы күрше участоклар арасында чикләүләр юк; г) башка очракларда чикләүләр юк. Сезгә муниципаль төзелеш нормалары белән танышырга киңәш итәбез һәм, хәтта хокук бозулар булмаса да, сез Россия Гражданнар кодексының 304 маддәсе нигезендә үз хокукларыгызны яклау өчен судка мөрәҗәгать итә аласыз. Әйтик, күршегезне койманы сүтмәскә, ә аны яктылыкны әйбәтрәк уздыра торган коймага үзгәртүне таләп итәргә.

? Минем ирем стаж буенча пенсиягә чыга. Болай 64 яшьтә генә чыгарга тиеш әле. Пенсия таныклыгын бирергә тиешләрме икән аңа?

Илсөя

Җавап:
– Пенсия таныклыгы 2015 елдан бирле бирелми. Аның урынына хәзер пенсионер таныклыгы бирелә. Бу документ, пенсиягә чыгу вакытына карамастан, барлык пенсионерларга да бирелергә тиеш. Сезгә Россия Социаль фондына яисә күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Таныклык алу өчен кирәк булган документлар: гариза, паспорт яисә шәхесне раслаучы башка документ; 21х30 мм фото; әгәр документны пенсионер үзе рәсмиләштермәсә, гариза тапшыручы кешенең нотариуста раслатылган ышаныч кәгазе һәм паспорты.

? Хезмәт хакым 19700 сум. 7100 сум алимент алам. Миңа Путин пособиесе тиешме?

Ландыш

Җавап:
– Аңлавымча, бу сорау аз керемле гаиләләр өчен 8–17 яшькә кадәрге балаларга бирелә торган айлык пособиегә кагыла. Пособие алу өчен Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон гариза бирергә яки яшәү урыны буенча Пенсия фондына яки күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә була. Гариза бирү дә җитә. Пенсия фонды тиешле органнардан кирәкле документларны үзе сората.

Әлеге пособие җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан азрак булганнарга бирелә. Айлык керемне исәпләү өчен, гаиләнең еллык керемен 12 айга һәм гаилә әгъзаларының санына бүләргә кирәк.

(19700 + 7100) / 2 = 13400 сум

Татарстанда яшәү минимумы – 13135 сум. Шулай итеп, сезнең гаилә кереме яшәү минимумыннан артык, һәм, кызганыч, сезгә бу пособие тиеш түгел.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

26 гыйнварда сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Фәния ӘХМӘТҖАНОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

kzn.ru

Стипендия алса, түләнәме?

Студент кызыбызга 80 яшен тутырган өлкән кешене тәрбияләгән өчен каралган 1200 сумлык компенсацияне рәсмиләштермәкче идек. Кызыбыз стипендия алып укый. Бу очракта аңа 1200 сумлык ул акча түләнерме?

Казаннан Фирая апагыз

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:
– 80 яшен тутырган өлкән кешене тәрбияләгән өчен түләнүче 1200 сумны рәсми рәвештә эшләмәүче һәркем, шул исәптән стипендия алып укучы студентлар да рәсмиләштерә ала. Бу акча пенсионерның пенсиясенә өстәлеп күчә. Аны тәрбияләүчегә исә моның өчен иминият стажы белән ел дәвамында 1,8 коэффицент күләмендә пенсия коэффициенты да өстәләчәк.

Ярамагач, ник саталар?

Күз тимәсен өчен бөти, күз ише әйберләрне машиналарга, киемнәргә такмаска, бу – ширек, дип гел әйтеп киләләр. Шул ук вакытта мәчет тутырып, шушы предметларны саталар, алыгыз, тагыгыз дип, реклама ясыйлар. Менә кайда инде дөреслек? Ярамагач, ул әйберләр ник чыгарыла соң?

Исемем редакция өчен генә

«Шамил» мәчете имам-хатыйбы Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин:
– Бүген кеше белеп тә, белмичә дә «ширек» сүзен куллана башлады. Һәр нәрсәне шуңа кайтарып калдыру омтылышы көчле. Күз тимәсен өчен билгеләнгән бөти кебек әйберләрне дә ширеккә санаучылар байтак. Догалар, Коръәннән сүрәләр язып, Аллаһның рәхмәтен өмет итеп, шуны үзең белән йөртү тыелмый һәм ул берничек тә ширек була алмый. Бу хакта хәдисләрдә дә әйтелә. Ибн Гомәр исемле сәхабә үзләре дога укый алмаган кешеләргә Коръәннән аятьләр язып, яннарына куя торган булган. Шул рәвешле үзең белән күз тимәсен өчен дога язылган әйберләр йөртү – ислам динендә электән киң таралган күренеш. Кешеләр аның файдасын да, шифасын да күргән. Иң мөһиме – аларның барысының да Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән эшләнүенә чын күңелдән ышану.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

«СӘЛАМ, РИМАН!»

ЮБИЛЕЕН БӘЙРӘМ ИТҮЧЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ ҮЗЕ ТУРЫНДА ҮЗЕ СӨЙЛИ

Инде менә өченче ел рәттән Яңа ел җиткәндә дус-ишләргә: «Туган көн белән котларга онытмагыз!» – дип әйтеп куя башладым. Мин ел башында, гыйнварда туган. Нинди генә якын дус булмасын, ул туган көнне онытырга мөмкин.

Кадерле коллегабыз, мөхтәрәм журналист, 50 ел гомерен татар матбугатына багышлаган Риман Солтан улы Гыйлемхановны матур юбилее белән котлыйбыз.

Кемнәргәдер сабакташ, кемнәргәдер чордаш, кемнәргәдер каләмдәш, бик күпләргә остаз булган кеше ул. «Газетагызны Риман язмаларын укыр өчен алдырам» дигән сүзләрне еш ишетәбез. Шулай икәненә дә ышанабыз. Тормышның үзе кебек катлаулы фәлсәфәләрен гади генә итеп ачып бирүче каләм ияләре күп түгел. Шуның белән һәр укучыга якын ул.

Туган көнең белән, Риман абый, Риман Солтанович! Укучыларыбыз әле озак еллар «Риман язганны укыр өчен» газетага язылсыннар иде. Иҗат уңышлары сиңа! Күңелеңдәге җылылыкны югалтмыйча, һәрвакыт җырлап яшәргә язсын!

Яратып, «ВТ»лылар

Әминем үземне якын иткән кешеләрдән җылы сүзләр ишетәсем килә. Мактасыннар димим, чөнки туган көннәрдә сиңа мәдхия җырлый башласалар, бик оялта. Үзең өчен генә түгел, дуслар өчен дә оят. Чөнки алар минем күңел булсын өчен арттырып сөйләячәк, ягъни баш миләренең күзәнәкләрен киереп, матур сүзләр эзләячәк, күпме нервы бетерәчәк. Болай бәргәләнү кемгә кирәк?!

Үзен бик яхшы белүче бердәнбер кеше – ул үзе. Хәтта инде 52 елга якын бергә яшәгән газиз хатыным Фәридә дә мине тулысынча белеп бетерми. Ул да минем өчен гаҗәеп бер табышмак кебек. Бәлки, шуңа күрә гомер буе бер-беребезгә таба атлыйбыздыр да. Бер-беребездән туймыйбыздыр да, аның – мине, минем аны күбрәк беләсем килә, дип әйтүем.

Фәридә «ВТ»ны укып бара, яхшы газета чыгарасыз, дип мактый. Күп кенә иҗат кешеләре гаиләсенә хас булганча, хатын – минем беренче тәнкыйтьчем. Язмаларны газетага биргәнче иң элек аңа укып чыгам, аның киңәшләрен истә тотып... үземчә язам. Һәм ул моны сизми. Алай гына да түгел: «Менә булган бит, ярый әле мине тыңлыйсың», – дип тә куйгалый. Ир белән хатын яши-яши әнә шулай бертөрле фикер йөртергә, уйларга өйрәнәдер һәм бер-береннән шикләнмидер инде ул.

Әгәр туган көнем алдыннан интервью бирсәм, миннән ни өчен журналистиканы сайлавым турында сорамый калмаслар иде. Әни әйтмешли, «ни дип ялганлар идем» икән? Әнием Дания – Арча районы Югары Масра мулласы Габдрахман кызы. Габдрахман бабай – Тукайның икетуганы. Бу хакта хәзергә җәелеп язып тормыйм. Күптән түгел «Буласы булган инде» дигән автобиографик әсәр язарга тотынган идем. Анда мулла кызы Дания белән булган хикмәтләргә шактый зур урын бирдем. Төгәлли алсам, дөньяга чыгар, укырсыз. Хәзергә шуны гына әйтим: бер яктан бик тыныч, сабыр тоелса да, әни бик шаян телле иде, матур итеп җырлый да иде. Балачакта безгә әкият сөйләгәндә, образларга кереп бетә иде ул. Төрле җәнлек-җанвар авазларын чыгарып сөйләр иде. Авыл хатыннары булып, артистлар булып сөйләшә башласа, атаклы пародиячеләр бер читтә торсын! Әтием Солтан исә иҗат белән яшәде. Әле сугыш тәмамлангач та аның «Тынычлык язы» дигән беренче шигырьләр җыентыгы чыкты. Гомер буе язды әти. Туган авылым Субаш-Атыда балалар йорты директоры булып эшләгәндә, ятимнәрнең күңеле булсын, иҗатка да тартылсыннар диптер инде, танылган артистларны, язучыларны очрашуга алып кайта иде ул. Ул вакытта бер генә авылның да шулкадәр тере җырчыларны, әдипләрне күргәне булмагандыр. Очрашуларга керми калмый идем мин. Илһам Шакировның «Менәргә иде Урал тауларына» җырын җырлавы, Әлфия Авзалованың без, сабыйларга, «Бәтиләр» дигән җырны өйрәтеп калдыруы бүгенгедәй хәтердә. Очрашудан соң әти кунакларны өйгә алып кайта иде. Чәй өстәле янында Сибгать Хәким, Мостафа Ногман, Зәки Нури, Мәхмүт Хөсәеннең шигырьләр укуын, Заһид Хәбибуллинның скрипкада халык көйләрен сыздыруын – барысын да хәтерлим әле. Мондый иҗади мохит киләчәктә нинди һөнәр сайлаячагыма йогынты ясамый калмагандыр.

Бишенче класста укыганда микән, яз турында шигырь язып, «Яшь ленинчы» газетасына җибәргән идем. Анда мондый юллар бар иде:

Салкын кыш үтеп китәр, / Җылы яз килеп җитәр.
Басуларда кар эрер, / Табигать язга керер.

Газетада чыгармадылар шигырьне, әмма редакциядән җавап килде. Ш.Маннапов дигән бер кеше: «Энем, кыш артыннан яз киләсе, кар эрисе болай да билгеле. Ул турыда шигырь язып та торасы юк», – дигәнрәк сүзләр язган иде. Әти белән әнинең: «Баланың күңелен кайтарырлык итеп язмаса да яраган булыр иде», – дип сөйләнүләрен ишетеп калдым, тик шагыйрь абыйга үпкәләмәдем. Алай гына да түгел, озак еллар кадерләп сакладым мин ул хатны. Казан хәтле Казаннан гади бер авыл малаена хат килсен әле! Авылда: «Риманга «Яшь ленинчы» гәҗитеннән хат килгән...» – дип ел буе сөйләүләре генә дә ни тора!

Туган көн алдыннан хатирәләр яңарту табигый инде ул. Без үткәнне барлый-барлый, алга барабыз. Ни гаҗәп, шул хатирәләрдән мәхәббәткә бәйлеләре аеруча еш калкып чыга. Урысча әйткәндә, нужәли шул хәтле любвиобильный булдым икән мин?! Әлбәттә, кызлар белән үбешкән булмады, мәктәптә укыганда, диюем. Татар авылында бу эш бозыклык та саналгандыр, бәлки. Әнә Туфан ага Миңнуллин да балачак истәлекләрендә, марҗа кызлары әйбәт үбешә дигәнне ишеткәч, урыс авылларына баргалавын язган иде. Бәлки, без дә баргалаган булыр идек, тик якын-тирәдә урыс авыллары юк иде. Ә беренче мәхәббәт хисләре уянып, күңел тынычлыгы югалган вакытларны хәтерлим әле. Безнең мәктәпнең беренче катында югары класста укучылар өчен танцылар оештыра башлаганнар иде. Патефоннан җибәргән музыка астында селкенергә, тора-бара вальс әйләнергә өйрәндек. Шул чакта кызлар биленә беренче мәртәбә кагылуым, бөтен гәүдәм дерелдәп куюы, каушаудан ык-мык килә башлавым әнә шул олы мәхәббәт хисенең беренче билгеләре булгандыр инде. Беренче мәхәббәтнең онытылмавы да ул хисне беренче тапкыр кичерүгә бәйле. Мин «ВТ»да сәер мәхәббәт турында язган идем инде. Ул бер танышымның картлык көнендә беренче мәхәббәтенең телефон номерын табып, сөйләшә башлавы турында иде. Юллары аерылганга 56 ел вакыт узгач бит бу! Инде менә өч ел сөйләшәләр, әмма күрешергә базмыйлар. Ни өчен? «Сәер мәхәббәт» дигән яңа хикәям дә шул хакта.

Әле сугыш чоры кызлары турында да язасым бар. Дөрес, шул исемдә китап чыгарган идем инде, тик анда сугыш нәтиҗәсендә ана булудан мәхрүм ителгән «кыз-әбиләр»нең исемлеге һәм алар турында кыскача гына мәгълүмат бирелгән иде. Хәзер шуны әдәби әсәр, бәлки, сәхнә әсәре итәсе килә. Ельцин әйтмешли, «так-шты» язасылар алда әле. Сулаганда сызгырган, йөргәндә шыгырдаган тавышлар ишетелсә дә, картаерга исәп юк.

18 гыйнварда үземә ничә яшь тулганын да язмыйм. Бер акыллы кеше миңа: «Алтмыш тулып узгач, яшең турында бик кычкырып йөрмә, хәтта дусларың арасында да кара көнчеләр булырга мөмкин, күз тигезмәсеннәр», – дигән иде. Шуңа күрә яшемне әйтмим, әти белән бер көнне туганымны әйтсәм генә инде. Ә ул 93 яшь тә 4 ай яшәде. Вафатына дүрт ай кала «Бәхет юлларымын» дигән шигырь язып, матбугатта бастырды.

Ярый әле үзем турында кешедән яздырмадым, мактатмадым. Туган көнемдә миңа «Сәлам, Риман!» – дип шалтыратучылар һәм матур, озын гомер теләүчеләр күп булыр әле. Ә иҗатыма мине укып белгән кешеләр бәя бирер.

Мин җырларга яратам, яшь чакта яхшы гына биюче дә идем. Университетның «Каз канаты» ансамблендә биеп йөрдем, халык уен кораллары ансамблендә авыз гармунында уйнадым, мандолина чиерттем һәм татар хорына йөрдем. Кайчан гына укыганмындыр, валлаһи. Сабакташлар: «Риман университетка җырлап керде, биеп чыгып китте», – дип сөйләп тә йөрделәр әле. Җырлап яшик. Әйдә, минем туган көн хөрмәтенә берне... җырлап куйыйк әле. Мин башлыйм, сез кушылыгыз!

Гомер үткән саен яшәрә күңел,
Ул – шулай мәңгегә шиңми торган гөл.
Яшәгән саен яшисе килә,
Яшәреп яшисе чын дуслар белән.

Хәзергә менә шул. Сезгә бәхет теләүче Риман дип белерсез.

СИН – ХАТЫН-КЫЗ!

Инде шактый еллар яралы язмышлар турында язсак та, яңалары белән танышкан саен тетрәнеп куясың. Ничек тә андый кешеләрне сөендерәсе, шатлык хисләре бүләк итәсе килә. Шул уйлар белән бер көнне «Ватаным Татарстан» белән матурлык көне» дип атадык. «ВКонтакте» челтәрендәге «Язмышлар чатында» сәхифәбез аша бер герой таптык та көнне аңа багышладык. «Матурлык көне»н Казанда яшәүче Миләүшә Наразинага бүләк иттек.

«Әле мин бирешергә җыенмыйм. Юлыма гел яхшы кешеләр килеп чыга», – ди Миләүшә.

Казанның бер салонында эшләүче Фирүзә Галиева аны бизәндерергә, Дилә Гыйльманова прическа ясарга ризалык бирде.

Язмышына үпкәсе юк Миләүшәнең. Бар теләге – ничек тә кызын үстереп, аякка бастырырга, аны тормыш итәргә өйрәтергә. 9 яшьлек кызы Амелиянең психик яктан тайпылышлары бар. Табиблар аңа «сенсомоторная алалия» диагнозы куйган. Ул дөрес итеп сөйләшә алмый, сорауларга төгәл җавап бирми. Кыскасы, яшьтәшләреннән нык аерыла. Балалар бакчасына йөргән. Мәктәпкә дә алып барганнар. Тик укый алмагач, белемне хәзер өйдә генә бирәләр икән.

– Кызымны бакчага 3 яше тулганда бирдек. Шул чакта мин аның үсеше бүенча башка сабыйлардан калышканын сизеп алдым. Сөйләшми, әйткәнне аңлап җиткерми. Бер почмакка утыра да үзе генә уйный. Гел бер әйберне кабатлап тора. Кыскасы, ул үз дөньясында яши, – ди Миләүшә.

Кызны башта психиатрга күрсәтәләр, аннары дефектологка алып баралар. Алар дәваларга киңәш итә. 3 айдан Амелия сөйләшә башлый. Кызындагы бу үзгәреш анага канат куя. Тернәкләндерү үзәкләрендә дә барып дәваланалар. Әмма язмыш тагын бер сынау әзерләп куя. Баласы хакына барысына да әзер булган хатынның ире җылыны читтән эзли башлый. Миләүшәгә каенанасы ярдәм күрсәтә.

– Мин әнигә бик рәхмәтлемен. Әти белән икесе дә ярдәм итеп торалар. Башта мин кызым белән аларның фатирында яшәдем. Соңрак, ярдәм итәр өчен, безгә күчтеләр. Бергә җиңелрәк. Мине бераз ял иттерер өчен, әни барысын да эшли. Андый кеше башка юктыр ул, – ди Миләүшә. – Әбисе белән бабасы кызымны да бик яраталар. Бердәнбер оныклары бит. Бала мәктәптә укый алмагач, өйдә торырга мәҗбүрмен. Җай чыккан саен, дәвалануга йөртәм. Шөкер, кызымның уңай якка үзгәрешләре шактый. Барысын да аңлатырга, өйрәтергә тырышам. Аның бит әле минсез дә яшисе булачак. Казанда Амелия кебек балаларны тормышка яраклашырга өйрәтәләр икән. Без дә бу үзәккә барырга чиратка бастык.

Миләүшә – Арча районының Утар Аты авылы кызы. Йортларында янгын чыгып, бернәрсәсез калгач, алар, Казанга китеп, кеше фатирына түләп яши башлый. Бераздан әнисе белән сеңлесе икесе бергә ипотекага фатир алалар. Әле дә шуны түлиләр икән.

– Әниемә ике тапкыр инсульт булды. Әле аңа 54 кенә яшь. Аягына басып, эшләп йөри алуына сөенәбез инде. Әтием миңа 13 яшь чагында үлгән иде. Аның юклыгына да 22 ел инде, – ди Миләүшә. – Балама 18 мең сум пенсия алам. Ул акча кызымны дәваларга җитми дә. Әле бит ашатасы да бар, киендерәсе дә. Әниләрендә торгач, ирем балама алимент түләми. Шулай килештек. Үзем дә яхшысынмыйм инде. Каенанам белән каенатам кирәк-яракны алалар, коммуналь хезмәтләргә түлиләр. Ашатып-эчертеп, яшәткәч ризамын. Мин үзем турында оныттым инде. Театр-концертларга бару, кафеларга йөрү минем өчен оят әйбергә әйләнде. Үземә яңа кием дә алганым юк. Дусларым, якыннарым үзләренекен бирә.

Матурлык салонына ул кызын ияртеп килде. Әбиләре эштә икән. Амелия телефон белән дус. Мультфильмнар карарга ярата. Әнисен бизәндереп бетергәнче, тыныч кына утырып тора алды. Чәчләрен дә ясап куйгач, Миләүшә көзгегә карады да: «Матур да, яшь тә икән бит мин», – диде. Йөзеннән елмаю китмәде. Бара да көзгегә карый. Шушы матур мизгелләрне бүләк итә алганга без дә сөендек. Матурлык салоныннан чыккач, аны бер изге күңелле ханым көтеп тора иде. Безнең «Язмышлар чатында» төркеме язылучысы икән. Яңа ел алдыннан алар белән Кыш бабайга хат язган идек. Миләүшә дә шунда үз теләген калдырган булган. Язылучыбыз, барысын да күзәтеп баргач, безне тиз тапты. Ул Миләүшәгә җылы спорт киеме алып килде. Хәйриячебез исемен язмауны үтенде.

Миләүшәгә тагын бер бүләк әзерләдек. Казандагы рестораннар хуҗабикәсе Резедә Хөсәенова безне кичке ашка чакырды. Андагы кызлар зурлап кунак иттеләр.

– Яңадан тормыш корырга уйлап та караганым булмады. Язмышым белән ризалаштым инде мин. Кайчак иремне дә сагынып куям. Бераз сабыр итә алмады шул. Миндә дә гаеп бар. Ул чакта бар тормышымны балама багышладым. Тизрәк терелтәсем килде, – ди Миләүшә. – Кечкенә чагында Амелия дә бөтенләй башка иде. Дәвалауларның файдасы бар, ул әкренләп кешеләргә ияләште, сөйләшә дә, аңлый да башлады. Димәк, тырышлык бушка китми. Әле мин бирешергә җыенмыйм. Юлыма гел яхшы кешеләр килеп чыга. Бүгенге кебек. Мине сайлап алып, онытылмаслык мизгелләр бүләк иткән өчен һәркемгә чиксез рәхмәт. Көнелем үсеп: «Мин – хатын-кыз!» – дип, өйгә кайтып китәм.

Һәр авылга бер Чулпан кирәк

Балтач районының Кариле авылында гомер итүче Чулпан Габделганиева белән шактый еллар аралашабыз. Республикада физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен нинди генә чара узмасын, анда Чулпанны очратмый калмыйсың.

«Татарстан энҗесе» бәйгесендә дә ул башта үзе катнашты, аннан инде үз районы кызларын алып килде. Йөгереп йөри торган, чыгып китәм дигәндә шалт кына машинасын кабызып җибәрүче кеше булса, аның нәрсәсе бар инде, дияр идек. Ә Чулпан тумыштан йөри алмый. Әмма кайбер сау-сәламәт кешеләр дә башкарып чыга алмаган эшләргә тотына ул.

Чулпан шигырьләр яза. Аның дүрт китабы дөнья күргән. Спорт белән дә дус. Шашка буенча Татарстан һәм Россия чемпионы. Тагын бер зур эше бар – ул районның «Фикердәш» клубын җитәкли. Ул аны үзе оештырган. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне бергә җыйган әлеге клуб үзенең 20 еллык юбилеен билгеләп үтте.

– «Фикердәш» клубы ачылган елларда без 5–6 кеше генә идек. Еллар узуга, безнең хакта ишетеп килә башладылар, – дип сөйли Чулпан. – Шунысы сөендерә: һәр чарага җыелган саен яңа дуслар барлыкка килде. Алар белән аралашып яши башладык. Хәзер инде бергә 60 кеше йөри. Араларында кемнәр генә юк: иҗат белән янучылар, спорт белән шөгыльләнүчеләр...

Чулпан сөйләвенчә, әлеге клубка килеп, ярларын тапкан кешеләр күп икән. Дистәгә якын гаилә корылган. Бергә йөргән һәркем якын кешегә әйләнә. Гел аралашып торалар, тормышта нинди генә хәл килеп чыкмасын, ярдәмләшәләр. «Бу эшләрне бергә үзем генә башкара алмас идем. Район хакимиятенә, «Факел» яшүсмерләр клубында эшләүчеләргә чиксез рәхмәтемне белдерәм. Бик күп алар», – ди ул.

Бәйрәм матур теләкләр һәм җырмоң белән үрелеп барды. Җырчылар һәркемнең күңелен күрде. «Фикердәш»ләр аларга ияреп җырлады да, биеде дә.

– Мин – авыру, дип утырып булмый. Башкалар кебек, җир җимертеп аралашасы да килә, сөйләшәсе дә, матур кичәләр дә уздырасы килә. Гомер бер генә бирелә бит. Әнә шуны уйлыйм да «Фикердәш»ләрне бик бәхетле итәсе килә, – ди Чулпан. – Дөнья шулкадәр матур. Аны яратып, тормыштан ямь табып, авыру-сызлануларны онытып торып, шатланып яшәргә язсын. Язмыш сынауларына дучар булгансыз икән, күңелегезне төшермәгез. Сынаулар артыннан җиңеллек килә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ИЛФАТ ӘСКӘРОВ:

«МИН – БИК ҮҖӘТ КЕШЕ»

«Яшь аралаш көлү» спектаклендәге (Рабит Батулла) Каракошны, «Диләфрүзгә дүрт кияү»дәге (Туфан Миңнуллин) Галимне, «Яратылмый калган ярлар»дагы (Булат Сәлахов) Алексейны күз алдыгызга китерегез әле. Берсе көнче, берсе – кызлар кулын да тотып карамаган галим, берсе – хиссез хәрби. Татарстанның атказанган артисты, Чаллы театры актеры Илфат ӘСКӘРОВның рольләре бу. Сәхнәдә рәхимсез дә, хыялый да була белгән артист бүген нинди уй-фикерләр белән яши? Чаллы театры нинди үзгәрешләр кичерә? Тамашачыны ничек җәлеп итәргә? Әңгәмә әнә шул һәм театр артистының зур кинода төшү тәҗрибәсе турында.

chelnyteatr.tatar

:: Чаллының үз театры бар, инде хәзер каланы таныткан «Брежнев шәһәре» дигән роман да бар. Ничек уйлыйсыз, Чаллыга тагын ниләр җитми?

– Чаллыда бар да бар, кайбер вакытларда игътибар да күбрәк булса… Театр каланчасыннан гына карасак та, ерактарак булгач, башкала театрлары кебек үк күз уңында түгел инде без. Әйе, яңа бинабыз да, милли йөзебез дә бар. Бездә милли үзан, бәлки, Казанныкына караганда да көчлерәктер. Чаллыда барыбер татарча күбрәк аралашалар. Безнең язучыларыбыз да, миңа калса, аерылып тора. Без, драма театры артистлары, әле һаман сәхнәдә дә, сәхнә артында да, урамда да татарча сөйләшәбез *(көлә)*.

:: «Шәһәр. Нокта. Брежнев» спектаклен тамашачы яраттымы? Гомумән, автокала тамашачысы ул нинди? Аңа нинди спектакльләр кирәк, ул буш вакытын ничек үткәрә?

– «Шәһәр. Нокта. Брежнев» спектакленең үз тамашачысы бар. Без аны пандемия чорында әзерли башладык, 700 битле романның һәр җөмләсен тикшереп, җентекләп эшләдек. Нәтиҗәдә ике тәнәфесле 4 сәгатьлек спектакль туды. Аның куелышы да үзенчәлекле, шуңа, бәлкем, тамашачыдан берникадәр әзерлек тә сорала торгандыр. Ул уйландыра да, әзгәләндерә дә, елмайта да – җыеп әйткәндә, көчле әсәр. Һәрхәлдә, минем өчен якын бу спектакль. Мин анда төп герой Артурның әтисе Вазыйхны уйнадым.

Чаллының тамашачысы бик гади ул һәм шул ук вакытта бик төрле. Кайберсенә Туфан Миңнуллинның «Без бит – авыл малае», «Диләфрүзгә дүрт кияү» кебек әсәрләре якынрак. Бер карагандa, бу дөрес тә. Барыбызны да тормыш проблемалары баскан, ил-көннәр дә тыныч түгел, кемнең инде театрда да проблема белән басыласы килсен?! Шунысы да бар бит әле: мәсәлән, фестивальләр өчен башкарак форматтагы спектакльләр кирәк, тамашачының күбесе халыкчан әсәрләр көтә. Шул ук вакытта бездә яңа форматта байтак спектакльләр чыкты: мәсәлән, «Ак калфак» (Мирхәйдәр Фәйзи), «Капка» (Айгөл Әхмәтгалиева), «Сихерче» (Нәбирә Гыйматдинова) – тамашачы аларны тын да алмый карап утыра, димәк, ни генә дисәк тә, тамашачыбыз зәвыклы безнең.

Чаллы тамашачысы – гаҗәеп музыкаль, театраль тамашачы ул. Гыйнвар каникулларында без моңа тагын бер кат инандык. Зал тутырып йөрделәр. Сүз уңаеннан, Яңа шәһәрдән ЗЯБ районындагы яңа бинага күченгәч, монда кеше йөрмәс инде дип, үзебез дә пошаманга калган идек. Йөри бит кеше! Бинасы да үзенә җәлеп итә, эчтәлеге дә үзенчәлекле.

:: «Брежнев» дигән сериал да чыга бит әле.

– 2023 елны «Брежнев» сериалын төшерүче «Триикс Медиа» продюсерлык компаниясе кастингка чакырды һәм Вазыйх Насихович роленә раслап та куйды. Башта ук, минем урысчам ипи-тозлык кына, татарча сөйләшәм, татарча фикерлим, минем белән җәфаланачаксыз, дип кисәтеп куйдым. Безгә шундый кеше кирәк, дигән булдылар инде. Башта алар бездә «Башыңа төшсә» (Раффи Шарт) дигән спектакльне карадылар. Анда да төп рольдә идем. Алар, син безгә туры киләсең, дигәч тә каршы булдым әле, үзебезнекеләр көчләп диярлек җибәрде. Ерып чыктык, Аллага шөкер. Узган елның декабрендә соңгы съемкалар булды. Әйтүләренчә, быел сентябрьдә дөнья күрәчәк.

> Бу сериалда да үсмерләр төркемнәре, «стрелка»лар, шәһәр төзелеше, заводязмышы, кешеләрнең гаепсездән гаепле калулары, әфган темасы, ата белән улның мөнәсәбәтләре – бар да бар. Әлбәттә, экранның тәэсир итү көче зуррак, бәлки ул популяр да булып китәр. Әмма хәзерге өй балаларына аның тәэсир көче зур булмас. Алар урамда үсми, күбрәк өйдә, компьютер алдында утыралар…

:: Телевидениедән киткәнгә үкенмисезме?

– Баштарак булгандыр инде. Мине дикторлыкка укыткан Эльмира Хамматова Чаллы театрына килгәч: «Балакаем, миннән монда качтыңмыни?» – дип куйгач та, ниндидер бер сагыну кузгалып алды. Мөгаен, дусларны сагыну булгандыр ул. «Туган җир» тапшыруын алып барган Рамил Гарипов, Раиф Гыймадиев белән бергә укмашып яшәдек бит. Без, мәдәният институтындагылар, бөтен тулай торакларны йөреп, милли-мәдәни үзәкләргә җыелышып аралаша идек. Шуңа күрә Казанда бик күп танышлар калды. Чаллыга исә өч курсташ килдек. Равил Гыйләҗев белән хәзер дә бергә эшлибез, Нияз Гыйсмәтуллин театрдан китте инде. Бу – 1996 нчы еллар, акча түләү юк, хезмәт хакын помидорлата, кыярлата, тавык ите белән дә алган чаклар. Театр шундый инде ул: бер эләктерсә җибәрми. Аннан соң кире Казанга чакырдылар, кире китеп булмады. Ул еллар артта калды, инде хәзер театрда үз сүзен әйтә алырлык артист булып җитештек. Әле ярый театр башка өлкәгә алмаштырылмаган, дим.

:: Актер булмасагыз, кем булыр идегез?

– Бөтен эшне эшләп була! Акчасыз заманнарда агач эшенә бирелеп киттем, тәрәзә рамнары, йөзлекләре ясадым, аннары түшәм тарттыру серләренә төшендем. Хатыным белән рам-багетлар ясау белән дә шөгыльләндек. Аннары тимерчелек белән җенләнеп алдым. Боларның барысын да белгәч, үз кулларың белән йорт салып та чыгып була икән. Өй салуга узган елны гына тотындым. Аңарчы барыбер, бәлкем, Казанга күченербез дигән өмет белән яшәлде…

:: Режиссер Олег Кинҗәгулов Чаллы театрына үзгәрешләр алып килде, аны кабул итүчеләр дә, итмәүчеләр дә булгандыр.

– Режиссерлар бит алар бу дөньяны без күргән кебек күрми, үзенчә күзаллый. Сер түгел, ул театрга яңа сулыш алып килде. Мин үзем аны башта кабул итә алмадым. Ә кабул иткәч… Мисал белән аңлатыйм әле. Мәсәлән, без бер әсәргә алындык, ди. Бер җөмләне укыйбыз да, ул: «Монда нәрсә эшлиләр?» – дип сорый. Син: «Ул ята, тора», – дигән буласың инде. Ул, юк, ди. Кайчак көн буе шул җөмләне тикшерәбез, ул һаман җавапларны кабул итми. Шул килеш өйгә кайтып китәсең, уйлыйсың, шул уйлар белән тагын эшкә киләсең. Җөмлә эчендә актарына торгач, әллә нинди мәгънәләре килеп чыга. Артист шул мәгънәгә барып җиткәнче, фантазиясен эшләтә, шуннан ниндидер хикмәт килеп чыга. Моннан соң инде артист белән режиссер арасында элемтә барлыкка килә. Бер дулкынга эләккәч, иҗат башлана. Миңа аның әнә шул ягы ошый. Без – аңардан, ул да бездән нәрсәгәдер өйрәнә. Иҗатта башкача булмый да инде.

:: Актерлык һөнәренең авыр һәм җиңел яклары әйтегез әле.

– Әгәр гаиләдә ир дә, хатын да бер өлкәдән булса, җиңел яклары шактый аның. Хатыным Чулпан да – актриса һәм без бер-беребезне аңлыйбыз. Арада профессиональ яктан да, ир белән хатын буларак та көнләшү юк. Һәрхәлдә, мин аның көнләшкәнен беркайчан да сизмәдем. Бәлки ул бардыр, сиздермидер. Спектакльдә мин түгел, минем персонаж яши. Ә персонаж гашыйк та була, үбешә дә, кочыша да. Әгәр хатын

бу персонажга көнләшү белән карый икән, димәк, әйбәт килеп чыккан. Ышандырып уйнамасаң, артист булырга кирәкми дә инде ул.

> Тормышында нинди хәл килеп чыкса да, артист аны сәхнәдә күрсәтми. Син әтиеңне җирләп килгән буласың, ә кичен халыкка комедия уйнарга кирәк. Һөнәрнең авырлыгы – әнә шулдыр.

Һөнәрнең җиңел яклары килсәк, ачык кеше булгач, минем дусларым күп. Танып ярдәм иткән вакытлар да шактый. Газ кертканда шулай булды, яхшы гына «скидка» ясадылар. Газобетон сатучы да төзелеш материалын арзан бәядән бирде. Әле бит үзе татар кешесе дә түгел, каян белгәндер. Ком ташучы да ярты бәядән сатып китте. Әле мин, беркатлыланып, фәлән абзый шундый гына бәягә сата дип, аның телефонын күршеләргә бирдем. Шуннан бу шалтыратып: «Әнем, ул бит сиңа гына шундый бәя», – дигәч, гаҗәпләндем инде. Күршеләр бер-берсен белми яши иде, һәрберсе белән танышып, хәл-әхвәлләрен белешеп йөри башлагач, аларда да шундый гадәт барлыкка килде. Һөнәрнең рәхәт яклары күп инде аның.

:: Һәр кеше нинди дә хәлиткеч минутлар кичерә. Шул минутта кемдер хәлиткеч киңәш бирә. Сезгә шундый киңәшне кем бирде?

– Мин үзем – Саба егете. Авыл тәрбиясен, ольлар сүзен сеңдереп үскән кеше. Хәлиткеч сүз дип әйтеп булмаса да, әти белән әни, авыл халкы алдында җаваплылык хисе көчле булды. Алар ни әйтер, дип яшәдек. Мансур малае болай иткән икән, дип көенеп сөйләүчеләр булмасын дип яшим. Улыма да шундый сабак бирәм. Әби киңәшләре, догалары һаман истә. Безне, биш баланы, әби тәрбияләде, әти-әни эштә булды. Ул кендек әбисе дә, дога белән өшкерә, куркулыклар да коя иде. Шуңа күрә бездән кеше өзелмәде. Кунып та калалар иде. Әбинең һәр хәрәкәте, кеше белән мөгамәләсе кечкенәдән безгә сеңгән.

:: Комачаулаган яисә ярдәм иткән гадәтегез бармы?

– Мин – бик уҗәт кеше. Максат куйсам, таш явамы, кармы, үз дигәнемә ирешмичә туктамыйм. Бу йорт салганда бик ярап куйды. Дөрес, сәламәтлеккә бик файдалы түгел инде ул, шулай да... Баярак көнчелек юк дип сөйләнсәм дә, анысы да булды. Дөрес, аны да яхшы якка борып була. Аннары дуслыкка бик җитди карыйм. Бәлкем, шуңадыр, чын дус дигәннәре берничә генә кеше.

:: Иң беренче роль нинди иде?

– Казанда уйнаган спектакльне алсак, «Диләфрүзгә дүрт кияү»дә – Амур, Чаллы театрында беренче ролем – балалар спектакленнән Мияубәк. Аның авторы Гөлсирә Солтанова тырышлыгы белән ул телевидениедә «Мияубәк һәм Чичиетта» дигән тапшыруга әйләнде.

:: Уңыш ул – тырышлыкмы, әллә язмышның сиңа хәерхаһлы булуымы?

– Барысы бергәдер. Һәрбер эштә 70–80% тырышлык кирәк дип уйлыйм. Калганы – сәләт.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ДЕМИДОВ ЮРИЙ ИВАНОВИЧ

(27.10.1938 – 17.01.2024)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Элекке ТАССР җирле сәнәгать министры Демидов Юрий Иванович 17 гыйнвар көнне 86 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Юрий Демидов 1938 елның 27 октябрендә ТАССР Лаеш районы Среднее Девятово авылында туган. Хезмәт эшчәнлеген туып-үскән авылында клуб мөдире булып 1956 елда башлап җибәргән. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайткач, комсомол эшендә булганнан соң, 24 яшендә «Комбайн» колхозы рәисе итеп билгеләнгән. 1968 елда КПССның Лаеш районы комитеты икенче секретаре итеп сайланган, ә ике елдан соң ТАССР Лаеш районы советы башкарма комитеты рәисе булган.

1976 елда КПСС Үзәк комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлагач, КПССның Югары Ослан районы комитеты беренче секретаре итеп билгеләнгән. Район җирлекләрен газлаштыру һәм төзекләндерү, социаль өлкә объектларын төзү, юл челтәрен үстерү, авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләү Юрий Ивановичның бу вазыйфасындагы нәтиҗәле эшчәнлегенең төп юнәлешләренә әйләнгән. Җирле халык аны бик хөрмәт иткән, чөнки ул гади хезмәтчәннәрнең мәнфәгатьләрен бик нык кайгырткан.

Юрий Демидов 1985 елда ТАССР җирле сәнәгать министры вазыйфасына билгеләнде. Аның актив катнашында республика сәнәгатен үзгәртеп кору буенча киң колачлы эш башкарылды, яңа производство куәтләре булдырылды, җитештерелә торган продукциянең ассортименты киңәйтелде. Аерым алганда, Кукмара шәһәрендә тимер савыт-саба җитештерү буенча яңа завод төзелде. Заводның продукциясе бүген дә бөтен илгә генә түгел, аннан читтә дә мәгълүм.

1989 елда Юрий Иванович «Татарместпром» җирле сәнәгать производство берләшмәсенә җитәкче итеп билгеләнде. Базар икътисадына күчү чорында бөтен тырышлыгын предприятиенең хезмәт коллективын һәм җитештерү мөмкинлекләрен саклауга юнәлтте.

Халык проблемаларына битараф кала алмаган кеше буларак, республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашты. X һәм XI чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Юрий Демидовның күпьеллык хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасыннан – «Почет билгесе» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен» һәм «ТАССР оештырылуга 100 ел» медальләре, «Татарстан Республикасының атказанган җиңел һәм текстиль сәнәгате хезмәткәре» дигән мактаулы исем, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы һәм башка бүләкләр.

Юрий Демидов эшенә тугрылыгы, профессионализмы, куелган максатка ирешүдәге ныклыгы белән аерылып торды. Эшлекле мөнәсәбәтләре һәм кешелеклелеге, ватанпәрвәрлеге, үзенә һәм үз кул астындагыларга карата таләпчәнлеге аңа коллегалары арасында, җәмәгатьчелектә зур абруй-хөрмәт китерде.

Демидов Юрий Ивановичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, О.В. КОРОБЧЕНКО, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, И.Ф. ЗАРИПОВ, М.Г. ЗЫЯТДИНОВ, А.П. ЛАВРЕНТЬЕВ, Ш.Р. АГЕЕВ, А.М. ПАХОМОВ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, «Татарместпром» акционер җәмгыяте президенты **ДЕМИДОВ Юрий Ивановичның** кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Ватаным Татарстан» газетасы коллективы, улы **МӘҮЛИЕВ Илшат Илдус улының** гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, газетада озак еллар буе эшләгән элекке хезмәттәшебез Фаршатова Люция Сафа кызының, якыннары һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу авыр көннәрне кичерергә сабырлык, ныклык бирсен, мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын.

Шигърият

Мин – гади бер юлчы...

Дифгать СИРАЙ

ҖИР ӘЙЛӘНӘ

Күпме гасыр буе Җир әйләнә,
Авыр йөген төяп елларның.
Алда әле, үз чиратын көтеп,
Азмы йөге тора дөньяның...

Җир әйләнә һаман,
Шатлыкларны,
Кайгыларны салып иңенә.
Аргандырмы – белмим,
Әмма еллар
Көч өстидер кебек үзенә.

Әйләнә ул,
Кояш яктысына
Киңрәк ачып үзенең кочагын.
Омтыла ул нурлар белән гүя
Тутырырга барлык почмагын.

МИН – ЮЛЧЫ

Тормышта мин – гади бер юлчы,
Башы юлның җирдә, шушында.
Юллар гүя метеор шикелле
Томырылып килә каршыма.

Кызу атлыйм, җитез атларга
Куша безгә үзе замана.
Үтим әле, үтим утыртып
Юл буена имән багана.

Шуңа карап барсын улларым,
Ерактан ук аны күрсеннәр.
Ярый икән моннан атларга,
Моннан кеше үткән, дисеннәр.

Үзләре дә китсен утыртып
Багананың ныгын, төзләрен.
Маяк булыр, җилгә-давылга
Куеп барганнарга йөзләрен.

Шулай атлыйм мин дә тормышта,
Киләчәккә таба йөз тотып.
Тик узгынчы түгел, юлчы мин:
Баганалар утәм утыртып.

НИГӘ СОҢ?

Болытлар агыла. Нигә соң
Түгел мин шул болыт, шул болыт?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Утырыр идем ак тау булып.

Яңгырлар шыбырдый. Нигә соң
Түгел мин шул яңгыр, шул яңгыр?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Яңгыратыр идем гел дәртле җыр.

Яшеннәр ялтырый. Нигә соң
Түгел мин шул яшен, шул яшен?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Чытырдар идем әй көн вә төн...

БИШ ТӘРӘЗӘ

Биш тәрәзә. Бишесендә
Биш кояш балкып яна.
Биш егет киткән бу өйдән,
Биш егет киткән яуга.

Һәр көн саен биш кыз үтә
Биш тәрәзә янынннан.
Бишесендә биш егетнең
Йөзе гүя чагылган.

Биш тәрәзә. Бишесендә
Биш кояш тора көлеп.
Балкыта шулай аларны
Сүрелми калган өмет.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: Чирмешән, Вафирә, Лаура, Мирас, әле, тән, Гоа, Алмаз, атом, Нәбирә, ни, Алтай, По, күркә, басынкы, имеш, аума, кичер, Лаишево, мәл, чалма, Сират, ил, Бану, ксут, трепак, Айнур, бавыр, Ләйна, кан, ара, арадашчы, йомырка.

Вертикаль: чардуган, Тантана, Лик, Имир, үкчәле, ел, Закир, ба, ләм, чак, Әлмәт, ат, елан, Балтач, Наилә, таушалу, Уренгой, им, двойка, Яра, Ом, башак, нар, Астра, па, Сарманай, Носов, оста, бина, Куприн, ым, Әлмәндәр, антиреклама.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Ир белән хатын

– Без бергә була алмабыз.
– Мәнә шуның өчен мин сине яратам да!

***

«Мондый егетең әле 100 булыр!» – дип әйтә иде әни. Тагын 85 калды.

***

Элек мин яратып һәм яратылып яшәргә хыялланa идем. Хәзер машинаны яңартырга хыялланам.

***

Мин ирләрнең чын йөзләрен бик тиз ачам. Нибары 1 атна минем белән аралашканнан соң, алар нервылы һәм борчулы кеше икәнлекләрен күрсәтә.

***

Гаиләдә хатын акчаны сөяркәгә җитмәслек итеп туздырырга тиеш.

***

Лилия олыгайды. Һәм подъездда аның исеме янына «апа» дип өсти башладылар.

***

– Син иртәгә бушмы?
– Әйе.
– Уйлаган идем аны бераугә дә кирәкмисеңдер дип.

***

Кешеләр ничек хыянәткә бара икән ул? Мин чәчемне башка җирдә алдырсам, үз чәчтарашымның күзенә карарга да куркам!

***

– Мин сине ничек танырмын соң?
– Буем – 165 см, авырлыгым – 54 кило.
– Яхшы. Мин ак пәлтәдән. Кулымда рулетка һәм бизмән булыр.

Беләсең килсә...

1 Рамазан аеннан соң нинди ай бара?
а) шәгъбан;
б) шәүвәл;
в) рәҗәб.

2 Аксельне кайсы спорт төрендә башкаралар?
а) кикбоксинг;
б) биатлон;
в) фигуралы шуу.

3 Пунт нәрсә ул?
а) шешә төбенең эчкә кереп торган өлеше;
б) борып ябыла торган шешә капкачы;
в) төрле төсләрдән торган шешә.

4 Казандагы 2 нче татар гимназиясе кем исемен йөртә?
а) Ризаэддин Фәхретдин;
б) Шиһабетдин Мәрҗани;
в) Каюм Насыйри.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. а); 4. б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының уэк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13856 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 206

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+